УТВЕРЖДЕНО и ВВЕДЕНО в действие
приказом заведующего Муниципального
бюджетного дошкольного образовательного
учреждения «Детский сад №3 «Кояшкай»
Чистопольского муниципального района
«01»09. 2022 г. №78
_______________ Г.И.Салахеева

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
«3 нче номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе

# «Салават күпере» исемле кечкенәләр төркемендә 2022-2023 нче уку елына

# «ТУГАННАН АЛЫП МӘКТӘПКӘ КАДӘР» ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ БУЕНЧА

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

**Тәрбиячеләр:**
**Сибгатуллина Р.М.**
**Мингулова А.Ш.**

**Чистай шәһәре, 2022**

**Эчтәлеге**

**I Максатлар бүлеге** ........ 3
1.1 Аңлатма язуы ........ 3
1.1.1 Программаның төп максатлары һәм бурычлары ........ 3
1.1.2 Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары ........ 4
1.1.3. Төркем эшчәнлегенең юнәлеше ........ 5
1.1.4 «Кояшкай» 3 нче балалар бакчасы турында гомуми белешмә ........ 5
1.1.5 3 – 4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре ........ 6
1.2 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре ........ 7
**II Эчтәлек бүлеге** ........ 8
2.1 Белем бирү өлкәләре һәм төп эшчәнлек юнәлешләре буенча белем бирү эчтәлеге ........ 8
2.1.1 Социаль-коммуникатив үсеш ........ 8
2.1.2 «Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсе ........ 8
2.1.3 «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе ........ 9
2.1.4 «Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе ........ 10
2.1.5 «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе ........ 13
2.2 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасын гамәлгә ашыру формалары, ысуллары, алымнары һәм чаралары ........ 14
2.3 Балалар бакчасының гаилә белән бәйләнешләре ........ 14
2.4. Төп юнәлешләр буенча перспектив планлаштыру ........ 16
2.4.1 Юлларда хәвеф - хәтәрсез йөрү кагыйдәләрен тәрбияләү ........ 16
2.4.2 Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру ........ 17
2.4.3 Физкультура-сәламәтләндерү эшчәнлеге ........ 18
2.5 Белем өлкәләре буенча календарь-тематик планлаштыру ........ 18
2.5.1 «Элементар математик күзаллауны формалаштыру» буенча перспектив планлаштыру ........ 18
2.5.2 Әйләнә-тирә белән таныштыру буенча перспектив планлаштыру ........ 21
2.5.3 Сөйләм телен үстерү буенча перспектив планлаштыру ........ 25
2.5.4 Рәсем ясау буенча перспектив планлаштыру ........ 29
2.5.5 Әвәләү буенча перспектив планлаштыру ........ 31
2.5.6 Ябыштыру (аппликация) буенча перспектив планлаштыру ........ 33
2.5.7 Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге буенча эшне планлаштыру ........ 34
2.5.8 Физик культура буенча эшне планлаштыру ........ 36
2.6 Балалар бакчасында этномәдәни эшчәнлек юнәлешләре ........ 39
**III Оештыру бүлеге** ........ 41
3.1 Көндәлек режим ........ 41
3.2 Балалар белән белем бирү эшчәнлеген оештыру ........ 41
3.3 Мәдәни-ял эшчәнлеге ........ 42
3.4 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасын гамәлгә ашыруның материаль-техник чаралар ........ 43
3.5 Кеченәләр төркемендә предметлы –тирәлек мохиты оештыру ........ 44
3.6 Методик материаллар һәм уку-укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин ителгәнлек ........ 44

# I Максатлар бүлеге

## 1.1 Аңлатма язуы

Эш программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасы Н. Е. Вераксы, Т. С. Комарова, М. А. Васильева, редакциясендә, Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә эшләнде.

Эш программасы икенче кечкенәләр төркеме өчен тәрбия – белем бирү процессын оештыру эшен һәм эчтәлеген билгели

Кеченәләр төркеме балаларын үстерү буенча эш программасы төп юнәлешләр - физик, социаль-коммуникатив, танып белү, сөйләм үсеше һәм сәнгать – эстетик юнәлешләре буенча яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, 3 яшьтән 4 яшькә кадәрге балаларның күпкырлы үсешен тәэмин итә.

Эш программасы 2022-2023 уку елына исәпләнеп төзелде.

Гамәлгә ашырыла торган программа өлкәннәрнең балалар белән хезмәттәшлегенең шәхси–үсеш һәм гуманистик характеры нигезендә төзелде.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыру буенча белем бирү учреждениесе эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше булып балаларны танып – белү-сөйләм үсеше тора.

### 1.1.1 Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максатлары һәм бурычлары— баланың мәктәпкәчә балачагын тулы канлы уздыру өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап үстерү, хәзерге җәмгыятьтәге тормышка әзерләү, уку эшчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.

Программада баланың шәхесен үстерүгә, балаларның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын таба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә.

Әлеге максатлар балалар эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында гамәлгә ашырыла.

Программаның максатларына ирешүдә түбәндәгеләр беренче дәрәҗә мөһим:

• һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту; • төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;

• балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбиябелем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;

• тәрбия-белем бирү процессын иҗади оештыру; • белем бирү материалын кулланунып вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;

• балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;

• мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм гаилә шартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;

• балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү.

Программада билгеләнгән тәрбия максатларын һәм бурычларын хәл итү бары педагог тарафыннан баланың мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендәге беренче көннәреннән үк балалар активлыгының төрле формаларын һәм инициативаларын системалы һәм максатчан яклавы нәтиҗәсендә генә мөмкин. Бала ирешәчәк гомуми үсеш дәрәҗәсе, аңа салынган әхлакый сыйфатларның тотрыклылыгы һәрбер тәрбиясенең педагогик осталыгына, аның культура дәрәҗәсенә, балаларга карата мәхәббәтенә бәйле. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагоглары гаилә белән берлектә, баланың сәламәтлеге һәм һәрьяклы тәрбиясе хакында кайгыртып, һәрбер баланың бәхетле балачагына омтылырга тиешләр.

Эш программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә кадәр» мәктәпкәчә белем бирүнең якынча төп гомуми белем бирү программасына нигезләнеп төзелгән. / Н.Е.Вераксы, Т.С Комарова, М.А.Васильева, редакциясендә, мәктәпкәчә белем бирү программасының – мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү структурасына - Федераль дәүләт таләпләренә туры китереп икенче кечкенәләр төркеме өчен төзелгән.

### 1.1.2 Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары

Программада белем бирүнең бала шәхесен формалаштыруны тәэмин итүче һәм педагогны аның индивидуаль үзенчәлекләренә юнәлтүче үстерү функциясе беренче планга чыга, бу балачакның мәктәпкәчә чорының үзкыйммәтен тану турындагы хәзерге фәнни «Мәктәпкәчә тәрбия концепциясе»нә (авторлары В.В. Давыдов, В.А. Петровский һ.б.) туры килә.

Программа балага карата гуманлылык һәм шәхес итеп карау мөнәсәбәтләрендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, шулай ук сәләтләрен һәм интегратив сыйфатларын формалаштыруга юнәлтелгән.

Эш программасы:

• баланың үсешенә ирешүне максат итеп куйган үсешкә китерүче белем бирү принцибына туры килә;

• фәнни нигезләнгәнлек һәм гамәлдә куллнучанлык принципларын исәпкә ала (Программаның эчтәлеге яшь чорлары психологиясе һәм мәктәпкәчә педагогиканың төп нигезләмәләренә туры килә һәм, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, массакүләм мәктәпкәчә белем бирү практикасында уңышлы гамәлгә ашырыла ала);

• тулылык, зарурлык һәм җитешлелек критерийларына туры килә (җитәрлек күләмдә «минимум» материал кулланганда, куйган максатлар һәм бурычларны хәл итәргә мөмкинлек биреп);

• мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү процессының тәрбияви, үсеш һәм укыту максатлары һәм бурычлары бергәлеген тәэмин итә, аларны гамәлгә ашыру барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсешенең нигезен тәшкил итүче сыйфатлар формалаша;

• балаларның яшь мөмкинлекләренә һәм үзенчәлекләренә, белем бирү өлкәләренең үзенчәлегенә һәм мөмкинлекләренә туры китереп, белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибын исәпкә алып төзелә;

• белем бирү процессын коруның комплекслы-тематик принцибына нигезләнә;

• программалы белем бирү бурычларын өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның мөстәкыйль эшчәнлегендә хәл итүне турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, мәктәпкәчә белем бирүнең үзенчәлегенә туры китереп, режим моментларын уздырган вакытта да күздә тота;

• белем бирү процессын балалар белән эшләүнең яшь үзенчәлекләренә туры килгән формаларын куллану аша оештыруны күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүнең төп формасы һәм алар эшчәнлегенең әйдәп баручы төре булып уен исәпләнә;

• төбәк үзенчәлекләренә бәйле рәвештә белем бирү процессын төрләндерүгә юл куя; • мәктәпкәчә яшьтәге барлык төркемнәр арасында һәм балалар бакчасы белән мәктәп арасында дәвамчанлыкны саклауны исәпкә алып төзелде.

### 1.1.3. Төркем эшчәнлегенең юнәлеше

Төркемнең эшчәнлеге төп гомумбелем бирү Программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә:

- «Закон об образовании в Российской Федерации» (Принят 29 декабря 2012года № 273-ФЗ);
- «Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных организациях» (Постановление от 15 мая 2013 года № 26 «Об утверждении СанПиН» 2.4.1.3049-13);
- Приказ Минобразования Российской Федерации «Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» от 17.10.2013 № 1155;
- «Закон РТ № 44 от 28.07. 2004 г. «О государственных языках РТ и других языках в РТ».
- Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Чистополь
- Приказ МБДОУ «Детский сад № 3 «Кояшкай» «О разработке примерной основной общеобразовательной программы дошкольного образования МБДОУ «Детский сад № 3 «Кояшкай».
- План работы МБДОУ «Детский сад № 3 «Кояшкай» на 2022-2023 учебный год.
- Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 3 «Кояшкай».

*Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге түбәндәге программаларга яраклаштырып төзелгән:*

• Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы «От рожения до школы» (под редакцией Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой Москва «Мозаика-Синтез», 2014

• Укыту-методик комплекты (УМК) «Туган телдә сөйләшәбез» Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ. – Казан: Фолиант, 2013.- 224 б.

• «Сөенеч» – «Радость познания» - мәктәпкәчә белем бирү өчен региональ мәгариф программасы. Автор Р.К. Шаехова.

• Балаларны татар теленә өйрәтү өчен «Уйный-уйный үсәбез» (УМК)

***Этно- культура*:**

Тәрбия һәм белем бирү бурычлары: Идел буе халыкларының (Россия, Татарстан, Чувашия, Башкортостан, Удмуртия, Марий Эль, Мордовия) музыкасы, әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте белән таныштыру. Патриотик хисләр: туган якка, туган телгә, туган илгә горурлык хисләре тәрбияләү; туган телдә сөйләшү теләге уяту.

Икенче кечкенәләр төркемендә Программаны тормышка ашыруның төп юнәлеше - балаларның танып белү, сөйләм, социаль-коммуникатив, сәнгати-эстетик, физик үсешенә шартлар тудыру. Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа буынның парциаль программалары нигезендә башка Программаның беренче планына белем бирүнең үстерешле функциясе куела. Программа балага гуманлы-шәхси позициясендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләре, компетенциясе, сәләте формалашуга юнәлгән.

Программада уен эшчәнлеге аерым урын алып тора, баланың туганнан алып мәктәпкәчә чорына кадәр белем һәм тәрбия бирү процессы комплекслы бирелгән.

Программаның төп максаты - күчүчәнлек принципын тормышка ашыру һәм белем бирү системасы концепциясенә яраклаштырып мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем бирү. Әлеге программаның аермалылыгы шунда: мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирүнең өзлексез булуы проблеманы чынлыкта тормышка ашыра. Программа Россия мәгариф академиясе тарафыннан тәкъдим ителгән.

### 1.1.4 «Кояшкай» 3 нче балалар бакчасы турында гомуми белешмә

*Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:*

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «3 нче номерлы «Кояшкай» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе.

*Кыскача атамасы:* «3 нче номерлы балалар бакчасы» МБМБУ

*Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы*:

субъект РФ: Татарстан Республикасы

индекс: 423980
шәһәр: Чистай
урам: Карл Маркс
йорт: 62/в
телефон: +7(843)-425-17-53
e-mail: Ds3.Chis@tatar.ru
сайт: edu.tatar.ru

*Эш программасын тормышка ашыру срогы - 1 ел (2022-2023 уку елы)*

**1.1.5 3 – 4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре**

3–4 яшендә бала әкренләп гаилә даирәсе чикләреннән чыга. Аның аралашуы аерым хәлләргә генә бәйле булмый башлый. Өлкән кеше, бала өчен гаилә әгъзасы гына булып калмыйча, билгеле бер иҗтимагый функция йөртүчегә әверелә. Баланың шундый ук функция башкару теләге аны реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтә эшчәнлекнең әйдәүче төренә әверелүче уен үсеше аша хәл ителә.

Шартлылык — уенның төп үзенчәлеге; бертөрле гамәлләрне бертөрле предметлар белән башкару аларны башка предметлар белән башкарылучы башка гамәлләргә кертүне күздә тота. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр уенының төп эчтәлеге уенчыклар һәм алмаш уенчыклар белән эш итүдән гыйбарәт. Уенның дәвамлылыгы зур түгел. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр бер-ике рольле һәм гади, җәенке булмаган сюжетлы уен белән чикләнәләр. Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый.

*Баланың сурәтләү эшчәнлеге аның предмет турындагы күзаллауларына бәйле*. Бу яшьтә әлеге күзаллаулар формалаша гына башлыйлар. График образлар ярлы. Бериш балаларның рәсемнәрендә детальләр булмый, башкаларның рәсемнәре күбрәк детальләштерелгән булырга мөмкин. Балалар инде төс кулланырга мөмкин.

*Вак моторика үсеше өчен әвәләп ясау зур әһәмияткә ия*. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр өлкән кеше җитәкчелегендә гади предметларны әвәләп ясарга сәләтле.

Аппликациянең аңга кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы мәгълүм. Бу яшьтә балалар аппликациянең гади төрләрен башкара алалар.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр конструкцияләү эшчәнлеге үрнәк буенча һәм уйланылганча катлаулы булмаган корылмалар төзү белән чикләнә.

Бу яшьтә перцептив эшчәнлек үсеш кичерә. Балалар эталон алды берәмлекләрен (предэталон) — аңга кабул итүнең индивидуаль берәмлекләрен файдаланудан сиземләү эталоннарына — аңга кабул итүнең культура буларак үзләштерелгән чараларына күчәләр. Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләр төркеменнән күчү ахырына балалар 5 һәм күбрәк формадагы предметларны, 7 һәм күбрәк төсне кабул итәргә, предметларны зурлыклары буенча аерырга, балалар бакчасы төркемендә һәм, белем бирү процессын билгеле бер тәртиптә оештырганда, бөтен мәктәпкәчә учреждение бинасында да ориентлашырга сәләтле. Хәтер һәм игътибар үсеш кичерә. Өлкәннәр соравы буенча балалар 3–4 сүзне һәм предметларның 5–6 атамасын истә калдыра алалар. Мәктәпкәчә кечкенәләр яше ахырына алар яраткан әсәрләреннән зур өзекләрне истә калдырырга сәләтле.

Күрсәтмә-гамәли фикерләү үсеше дәвам итә. Ситуацияләрне үзгәртү күп очракларда көтелгән нәтиҗәне исәпкә алып, максатчан сынаулар нигезендә гамәлгә ашырыла. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешләрне һәм мөнәсәбәтләрне билгеләргә сәләтле.

Мәктәпкәчә яшьтәге кечкенәләрдә хыял үсеше башлана. Уенда, бер төрле объектлар башкаларын алыштырганда, хыял аеруча ачык чагыла.

Балаларның үзара мөнәсәбәтләре нормалар һәм кагыйдәләр белән бәйле. Максатчан йогынты нәтиҗәсендә балалар чагыштырмача күп санда нормалар үзләштерә алалар, ул нормалар шәхси гамәлләрне һәм башка балаларның гамәлләрен бәяләү өчен нигез хасил итәләр.

Балаларның үзара мөнәсәбәтләре уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Актив рәвештә үзара багланышларга керүгә караганда, алар янәшә уйнауга ныграк тартылалар. Шулай да әлеге яшьтә үк үзара мөнәсәбәтләрне тотрыклы рәвештә сайлап кору күзәтелергә мөмкин. Балалар арасындагы низаглар башлыча уенчыклар аркасында килеп чыга. Баланың яшьтәшләре төркемендәге урыны күп очракта тәрбияче фикере белән билгеләнә.

Мәктәпкәчә кечкенәләр яшендә чагыштырмача гади ситуацияләрдә үзүзеңне тоту мотивларының бер үк вакытта бер үк нәрсәгә буйсындырылганлыгын күзәтергә мөмкин. Үз-үзеңне тоту белән аңлы рәвештә идарә итү әле формалаша гына башлый; күпчелек җәһәттә баланың үз-үзен тотышы ситуацияләргә бәйле. Шул ук вакытта баланың, телдән бирелгән күрсәтмәләргә кушылып, омтылышларын үзе үк чикләү очракларын күзәтергә мөмкин. Үз-үзеңне бәяләү үсеше башлана, бу очракта балалар күбесенчә тәрбияче бәяләмәсенә ориентлашалар. Шулай ук аларда җенси идентификация үсеше дәвам итә, бу исә сайлап алынган уенчыклар һәм сюжетлар асылында чагылыш таба.

## 1.2 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре

*Максат ориентирлары*

• Бала әйләнә-тирә предметлар белән кызыксына һәм алар белән актив эшли; уенчыклар һәм башка предметлар белән эмоциональ эш итүгә тартыла, үз хәрәкәтләре нәтиҗәсендә нәрсәгәдер ирешүдә үзсүзлелек күрсәтергә омтыла.

• Предметларга карата махсус үзләштерелгән гамәлләр куллана, көнкүреш предметларының (кашык, тарак, карандаш һ.б.) кулланылышын белә һәм алардан файдалана ала. Үз-үзенә хезмәт күрсәтүнең иң гади күнекмәләренә ия; көнкүрештә һәм уенда мөстәкыйль булырга омтыла; пөхтәлек күнекмәләрен күрсәтә.

• Дорфалыкка, саранлыкка карата тискәре мөнәсәбәт белдерә.

• Элементар әдәплелек кагыйдәләрен үти (мөстәкыйль яисә искә төшереп, «рәхмәт», «исәнмесез», «хушыгыз», «хәерле төн» (гаиләдә, төркемдә) дип әйтә; бакчада, өйдә, урамда элементар үз-үзен тоту кагыйдәләре турында беренчел күзаллауларга ия һәм аларны үтәргә тырыша.

• Аралашуда актив сөйләмгә ия; сораулар һәм үтенечләр белән мөрәҗәгать итә ала, зурлар сөйләмен аңлый; әйләнә-тирәдәге предметлар һәм уенчыкларның исемнәрен белә. Сөйләм башка балалар белән аралашуда тулы канлы чарага әверелә.

• Зурлар белән аралашырга омтыла, һәм хәрәкәтләрдә, һәм гамәлләрдә актив рәвештә аларга охшарга тырыша; бала зурлар гамәлләрен кабатлап күрсәтә торган уеннар барлыкка килә. Зурлар тәкъдим иткән уенга эмоциональ тартыла, уен кагыйдәләрен кабул итә.

• Яшьтәшләре белән кызыксына; аларның эш-гамәлләрен күзәтә һәм аларга охшарга тырыша. Яшьтәшләре белән аларга комачауламый гына янәшә уйный белә. Зур булмаган төркемнәр белән уртак уеннарга карата кызыксыну күрсәтә.

• Әйләнә-тирә табигать дөньясы белән кызыксына, ел фасылларына кагылышлы күзәтүләрдә кызыксынып катнаша. • Шигырьләргә, җырларга һәм әкиятләргә, рәсемнәр карауга кызыксыну белдерә, музыка тавышына хәрәкәтләр ясарга омтыла; төрле мәдәният һәм сәнгать әсәрләренә эмоциональ мөнәсәбәтен белдерә.

• Курчак театры геройлары гамәлләрен аңлап күзәтә; театральләштерелгән һәм сюжетлы-рольле уеннарда катнашырга теләк белдерә.

• Продуктив эшчәнлек белән (рәсем ясау, әвәләү, конструкцияләү, аппликация) кызыксына.

• Балага эре моторика хас, ул төрле төрдәге хәрәкәтләрне үзләштерергә омтыла (йөгерү, үрмәләү, атлап чыгу һ.б.). Гади эчтәлекле, катлаулы булмаган хәрәкәтле уеннарда кызыксынып катнаша

## II Эчтәлек бүлеге

### 2.1 Белем бирү өлкәләре һәм төп эшчәнлек юнәлешләре буенча белем бирү эчтәлеге

#### 2.1.1 Социаль-коммуникатив үсеш

«Социаль-коммуникатив үсеш, әхлакый һәм рухи кыйммәтләрне кертеп, җәмгыятьтә кабул ителгән нормаларны һәм кыйммәтләрне үзләштерүгә; баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм үзара бәйләнешен үстерүгә; мөстәкыйльлеген, максатчанлыгын һәм үз гамәлләрен үзе җайга салуын булдыруга; социаль һәм эмоциональ интеллектны, киң күңеллелекне, хәлгә керә белүне үстерүгә, яшьтәшләре белән уртак эшчәнлеккә әзерлек формалаштыруга, Оешмадагы балалар һәм өлкәннәр бергәлеге һәм үз гаиләләренеке булу хисен һәм аларга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә; хезмәтнең һәм иҗатның төрле төрләренә уңай караш формалаштыруга; көнкүрештә, социумда, табигатьтә үз-үзеңне имин тоту нигезләрен булдыруга юнәлтелгән»

***Төп максатлар һәм бурычлар***

*Социальләштерү, аралаша белү сыйфатларын үстерү, әхлак тәрбиясе*. Җәмгыятьтә кабул ителгән нормалар һәм кыйммәтләрне үзләштерү, балада рухи һәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, аны үз гамәлләрен һәм яшьтәшләре гамәлләрен дөрес бәяли белергә өйрәтү.

Баланың өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашуын һәм үзара бәйләнешләрен үстерү, социаль һәм эмоциональ интеллектны, киң күңеллелекне, хәлгә керә белүне, әйләнә-тирәдәгеләргә ихтирамлы һәм дустанә мөнәсәбәтне үстерү.

Балаларда уртак эшчәнлеккә әзер булучанлык тәрбияләү, уртак фикергә килү, яшьтәшләре белән конфликтларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә өйрәтү.

*Бала гаиләдә һәм берләшмәдә.* «Мин» образын, үз гаиләсенеке һәм оешмадагы балалар һәм өлкәннәр бергәлегенеке булу хисе һәм аларга ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү; үзенең аерым җенескә каравын (гендер аерымлыгы), аерым гаиләнеке булуын аңлау формалаштыру.

*Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек, хезмәт тәрбиясе*. Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен үстерү; мөстәкыйльлек, максатка юнәлгәнлек һәм үз гамәлләрен үзе җайга сала белү сәләте тәрбияләү.

Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләү. Хезмәтнең һәм иҗатның төрле төрләренә уңай фикердә булуны формалаштыру, хезмәткә уңай мөнәсәбәт, хезмәт итүгә теләк тәрбияләү.

Үз хезмәтенә, башка кешеләр хезмәтенә һәм аның нәтиҗәсенә хөрмәт белән карау тәрбияләү. Йөкләнгән бурычны (эшне ахырына җиткерә белү сәләте һәм теләге, аны җиренә җиткереп башкару омтылышы) үтәүгә җаваплы карарга өйрәтү.

Өлкәннәр хезмәте, аның җәмгыятьтәге һәм һәр кешенең тормышындагы урыны хакында беренчел күзаллаулар булдыру.

*Куркынычсызлык нигезләрен формалаштыру.* Көнкүрештә, социумда, табигатьтә куркынычсызлык тәртибе турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

Кешегә һәм әйләнә-тирә мохиткә куркыныч янау ихтималы булган хәлләргә карата сак мөнәсәбәт формалаштыру.

Кайбер типик хәвефле хәлләр һәм шул хәлләрдә үз-үзеңне тоту ысуллары турында күзаллаулар формалаштыру.

Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында элементар күзаллаулар формалаштыру; бу кагыйдәләрне үтәүнең зарурлыгына карата аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

#### 2.1.2 «Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсе

«Танып белү үсеше баланың мәнфәгатьләре, кызыксынучанлыгы һәм танып белү омтылышы үсешен; танып белү гамәлләре, аңы формалашуын; хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен; үзе, башка кешеләр, әйләнә-тирәдәге объектлар, әйләнә-тирәдәге объектларның үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт, хәрәкәт һәм тыныч халәт, сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.), туган җир һәм Туган ил турындагы беренчел күзаллаулары, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, Ватаныбызның традицияләре һәм бәйрәмнәре, кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, аның табигатенең үзенчәлекләре, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турындагы күзаллаулары формалашуын күз алдында тота»

***Төп максатлар һәм бурычлар***

*Элементар математик күзаллаулар формалаштыру*. Элементар математик күзаллаулар, әйләнә-тирә объектларының төп сыйфатлары һәм бәйләнешләре: форма, төс, үлчәм, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт турындагы беренчел күзаллаулар формалаштыру.

*Танып белү-тикшеренү эшчәнлеген үстерү*. Балаларның танып белү омтылышын үстерү, тирәлектә ориентлашу тәҗрибәсен киңәйтү, сиземләү үсеше, кызыксынучанлык һәм танып белү нигезен үстерү; танып белү гамәлләрен, аңны формалаштыру; хыялны һәм иҗади активлыкны үстерү; әйләнә-тирә объектлары, әйләнә-тирә объектларының үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.) турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.

Аңга кабул итүне, игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, әйләнә-тирә предметларының һәм күренешләренең үзенчәлекле, мөһим билгеләрен анализлау, чагыштыру, аерып күрсәтү, предметлар һәм күренешләр арасындагы иң гади бәйләнешләрне ачыклау, иң гади гомумиләштерүләр ясый белү сәләтен үстерү.

*Предметлы тирәлек белән таныштыру*. Предметлы тирәлек белән таныштыру (предметның аталышы, функциясе, кулланылышы, сыйфатлары); предметны кеше фикерләве һәм хезмәт нәтиҗәсе буларак кабул иттерү.

Предметлы тирәлекнең күптөрлелеге, кешенең, тормышны җайлырак һәм уңайлырак итеп, үзе һәм башка кешеләр өчен предметлы тирәлек тудыруы, аны үзгәртүе һәм камилләштерүе турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Предметлар дөньясы һәм табигый дөнья арасындагы сәбәпнәтиҗә бәйләнешен ачыклый белү сәләтен үстерү.

*Социаль дөнья белән таныштыру.* Әйләнә-тирә социаль мохите белән таныштыру, балаларның белем дәрәҗәсен киңәйтү, дөньяның тулай картинасын формалаштыру. Туган җир һәм Туган ил турында беренчел күзаллаулар, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, илебезнең традицияләре һәм бәйрәмнәре турында күзаллаулар формалаштыру. Гражданлык мөнәсәбәтен формалаштыру; Ватанга мәхәббәт, аның казанышлары белән горурлану, патриотик хисләр тәрбияләү. Кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

*Табигать дөньясы белән таныштыру*. Табигать һәм табигать күренешләре белән таныштыру. Табигать күренешләре арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклый белү сәләтен үстерү. Җир планетасының табигый күптөрлелеге турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Элементар экологик күзаллаулар формалаштыру. Кешенең табигатьнең бер өлеше булуын, аның табигатьне сакларга һәм якларга тиешлеген, табигатьтә бар нәрсәнең дә үзара бәйле булуын, кешенең Җирдәге тормышының күп очракта әйләнә-тирә дөнья белән бәйлелеген аңлауны формалаштыру. Табигатьтә үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләре формалаштыру. Табигатькә карата мәхәббәт, аны саклау теләге тәрбияләү.

### 2.1.3 «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе

«Сөйләм үсеше аралашу һәм мәдәният чарасы буларак сөйләмгә ия булуны; актив сүзлекне баетуны; бәйләнешле, грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик сөйләмне; сөйләм иҗаты үсешен; сөйләмнең аваз һәм интонация культурасы, фонематик ишетү сәләте үсешен; китап культурасы, балалар әдәбияты белән танышуны, балалар әдәбиятының төрле жанрлары текстларын ишетеп аңлауны; укырга-язарга өйрәтүнең алшарты буларак авазлы аналитик-синтетик активлык формалашуны үз эченә ала»

***Төп максатлар һәм бурычлар***

*Сөйләм үстерү*. Өлкәннәр һәм балалар белән ирекле аралашуны үстерү, тирә-юньдәгеләр белән үзара тәэсир итешүнең конструктив ысулларына һәм чараларына ия булу. Балаларда сөйләм теленең барлык компонентларын: сөйләмнең грамматик төзелешен, бәйләнешле сөйләмне — аның диалогик һәм монологик формаларын үстерү; сүзлек запасы формалаштыру, сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләү. Тәрбияләнүчеләрнең гамәли рәвештә сөйләм нормаларына ия булуы.

*Матур әдәбият.* Укуга карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү; әдәби сөйләмне үстерү. Матур әдәбият әсәрләрен тыңлау теләге һәм тыңлый белү, вакыйгалар барышын күзәтә белү сәләте тәрбияләү.

Яңа әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр тыңлый, вакыйга үсешен күзәтә, әсәр геройларының кичерешләрен уртаклаша белү сәләте тәрбияләү. Балаларга персонажларның гамәлләрен һәм бу

гамәлләрнең нәтиҗәләрен аңлату. Балаларга сүзләрне һәм әйтү өчен катлаулы булмаган гыйбарәләрне әйтеп бетерү мөмкинлеге биреп, укылган әсәрдән иң кызыклы, тәэсирле өзекләрне кабатлау.

Тәрбияче ярдәмендә халык экиятләреннән кечерәк өзекләрне сәхнәләштерергә һәм уйнап күрсәтергә өйрәтү. Балаларны яттан мәзәкләр һәм кечерәк шигырьләр сөйләргә өйрәтү.

Китапларга карата кызыксынучанлык формалашуга булышуны дәвам итү. Балалар белән даими рәвештә иллюстрацияләр карау.

***Тәкъдим ителә торган әсәрләр:***

***Балаларга уку өчен:***

*Җырлар, такмаклар, эндәшләр, бармак уеннары;* "Әлли-бәлли итәрсең...", "Тилгән...", "Салкын су, чиста су...", "Бас ,кызым, Әпипә..." "Әтисе дә ярата...", "Әйдә, әйдә, Зөбәйдә...", "Песи, песи пескәем...", "Минем кызым дәү кебек", "Күзгегә карыйм эле...", "Чәбәк – чәбәк әбкәсе..." "Там, там ,тамчы, там...", "Гөлдергү, гөлдергү...", "Суы сарыксын...", "Минем кызым бик иркә...", "Бармак, бармак, кайда булдың?", "Олыга утын ярырга...".

*Әкиятләр:* Татар халык әкиятләре: "Аю белән бабай", "Кыз һәм икмәк", "Аю белән хатын", "Мәче белән аю", "Кем нәрсә ярата?", "Төлке белән Каз", рус халык әкиятләре: "Шалкан", "Чуар тавык", "Өч аю".

*Шигърият:* М.Фәйзуллина. "Көзге яңгыр"; Р.Харис. "Лап-лап"; Ә.Исхак. "Чишмә"; Н.Каштан. "Безнең сыер"; Ә.Исхак. "Беренче рәхмәт"; З.Туфайлова. "Шофер булам"; З.Гомәрова. "Ул шуңа кечкенә"; Э.Мөэминова. "Үз телеңдә сойләшә"; Р.Харис. "Ботка"; Р.Вәлиева. "Минем сеңелем"; М.Мазунов. "Энесенә ул апа"; Б.Рәхмәт. "Су", "Ләлә чана шуа"; Һ.Такташ. "Ләйлә". Ә.Рәшит. "Кыш бабай" Ж.Тәрҗеманов. "Үзен бик чиста йөртә"; М.Мазунов."Кәҗә"; Д.Гарифуллин. "Тавыклар белән Таһир"; Х.Халиков. "Зиләнең курчагы"; Ж.Дәрзаман. "Алмаз"; М.Фәйзуллина. "Тәти кул"; Ә.Ерикәй. "Тышта яз"; З.Гомәрова. "Минем бүләк"; Ә.Кари. "Ике кыз"; Х.Вахит. "Уңган сыерчык"; Г.Насыйбуллин. "Әнигә булышам"; Ә.Бикчәнтәева. "Минем бакчам"; Г.Таһирова. "Йокла,курчак"; Ә.Кари. "Курчак"; Р.Вәлиева. "Сүз тыңлаучан булыгыз"; Р.Харис. "Башмак кигәндә"; Ф.Яруллин. "Ап-ак иткән" А.Барто "Әни белән сөйләшү", Ә.Юныс тәрҗемәсе.

*Чәчмә әсәрләр. Әдәби әкиятләр:* Д.Аппакова." "Рөстәм"; Г.Бакир. "Сания инде зур үсте"; М.Әмир. "Бәби әйтә"; Р.Гыйззәтуллин. "Кечкенә Ринат"; А.Алиш. "Куян кызы"; Р.Батулла. "Елак әтәч"; Р.Гыйззәтуллин. "Айсылу"; Р.Ишморатова. "Яңа чана"; Г.Лотфи. "Песнәк белән Әнисә"; Г.Бакир. "Сания бакчага бара"; А.Әхмәт. "Минеке, тимә"; Ж.Тәрҗеманов. "Йокы бабай"; А.Алиш. "Чукмар белән Тукмар"; И.Шәймөхәммәтов. "Мактанчык бака"; Ш.Перро. "Кызыл калфак", З.Садыйкова тәрҗемәсе; К.Ушинскийдан. "Әтәч үзенең гаиләсе белән", "дару", "Бергә җайсыз, аерым күңелсез".

***Яттан өйрәнү өчен***

*Татар халык авыз иҗаты:* "Яңгыр ,яу!", "Бу бармак...", "Песи-Нечкәбил..."; Ә.Ерикәй. "Көз"; Ә.Бикчәнтәева. "Туп"; Ш.маннур. "Яратам"; Ә.Бикчәнтәева. "Салкын, саф һава"; Б.Рәхмәт. "Кыш бабай"; Н.Исәнбәт. "Куянкай"; З.Туфайлова. "Әни сүзе"; Б.Рәхмхт. "Яз"; Г.Лотфи. "Әтәч".

### 2.1.4 «Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе

Сәнгати-эстетик үсеш сәнгать (сүз-тел сәнгате, музыкаль, сынлы сәнгать) әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартлары үсешен; әйләнә-тирә дөньяга карата эстетик мөнәсәбәт барлыкка килүне; сәнгать төрләре турында элементар күзаллаулар формалашуны; музыканы, матур әдәбиятны, фольклорны аңга кабул итүне; әдәби әсәрләр персонажларының кичерешләрен уртаклашуны стимуллаштыруны; балаларның мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тота»

***Төп максатлар Һәм бурычла*р** Әйләнә-тирә чынбарлыкның эстетик ягына карата кызыксынучанлык, әйләнә-тирә дөнья предметларына һәм күренешләренә, сәнгать әсәрләренә карата эстетик мөнәсәбәт формалаштыру; нәфис-иҗади эшчәнлеккә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.

Балаларның эстетик хисләрен, сәнгати кабул итүен, образлы күзаллауларын, хыялларын, иҗади сәләтләрен үстерү.

Балалар иҗатын, мөстәкыйль иҗади (сурәтләү, конструкцияләү-модельләү, музыкаль һ.б.) эшчәнлеккә карата кызыксынуны үстерү; балаларның үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗын канәгатьләндерү.

*Сәнгатькә тарту*. Әдәби һәм музыкаль әсәрләрне, әйләнә-тирә дөньяның, сәнгать әсәренең матурлыгын эмоциональ бәяләүне үстерү.

Илебез һәм чит илләр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру аша балаларны халык сәнгатенә һәм профессиональ сәнгатькә (сүз-тел, музыкаль, сынлы сәнгать, театр сәнгатенә, архитектурага) тарту; сәнгать әсәрләренең эчтәлеген аңлый белү сәләте тәрбияләү.

Сәнгатьнең төрләре һәм жанрлары, сәнгатьнең төрле төрләрендәге тәэсир итү чаралары турында элементар күзаллаулар формалаштыру.

*Сурәтләү эшчәнлеге.* Сурәтләү эшчәнлегенең төрле төрләренә карата кызыксынуны үстерү; рәсем ясау, әвәләү, аппликация, гамәли иҗат күнекмәләрен камилләштерү.

Сынлы сәнгать әсәрләре белән танышканда эмоциональ тоемлый белү сыйфатын тәрбияләү.

Коллектив эшләр башкарганда яшьтәшләре белән бергәләп эшләү теләге һәм эшли белү сыйфаты тәрбияләү.

*Конструкцияләү-модельләү эшчәнлеге.* Конструкцияләүгә тарту; конструкцияләү эшчәнлегенә карата кызыксынуны үстерү, конструкторларның төрле төрләре белән таныштыру.

Коллектив эшләү, үз эшләнмәләреңне гомуми ният кысаларында берләштерү, эшнең кайсы өлешен кем башкарачагы турында сүз куеша белү сыйфаты тәрбияләү.

*Музыкаль эшчәнлек*. Музыкаль сәнгатькә тарту; музыка сәнгатен кыйммәт-мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартларын үстерү; музыкаль культура нигезләрен формалаштыру, элементар музыкаль төшенчәләр, жанрлар белән таныштыру; музыка әсәрләре белән танышканда эмоциональ тоемлый белү сыйфатын тәрбияләү.

Музыкаль эшчәнлек өчен зарур сыйфатлар: шигъри һәм музыкаль тоем, ритм хисен, музыкаль хәтерне үстерү; җыр зәвыгы, музыкаль зәвык формалаштыру.

Музыкаль-сәнгати эшчәнлеккә карата кызыксыну тәрбияләү, эшчәнлекнең бу төрендәге күнекмәләрне камилләштерү.

Балалар музыкаль-нәфис иҗатын үстерү, балаларның мөстәкыйль иҗади эшчәнлеген гамәлгә ашыру; үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗын канәгатьләндерү.

Балаларда музыканы эмоциональ кабул итү тәрбияләү.

Өч музыкаль жанр — җыр, бию, марш белән таныштыру. Музыкаль хәтерне үстерүгә булышлык итү. Таныш җырларны, пьесаларны танып алу сәләте, музыканың характерын (күңелле, дәртле, тыныч) тоемлау, аңа эмоциональ мөнәсәбәт белдерү формалаштыру.

*Тыңлау.* Музыкаль әсәрне ахырынача тыңлап бетерергә, музыка характерын аңларга, әсәрдә ничә өлеш булуын белергә һәм ачыкларга өйрәтү.

Октава — септима чикләре эчендә авазларны югарылык буенча аеру, көй яңгырашындагы үзгәрешләрне (көчле, акрын) тою сәләтен үстерү. Төрле музыкаль уенчыклар, балалар музыка уен кораллары (музыкаль чүкеч, шарманка, шалтыравык, барабан, шөлдерле барабан, металлофон һ.б.) яңгырашын аеру сәләтен камилләштерү.

*Җырлау*. Җырлау күнекмәләрен үстерүгә: ре (ми) — ля (си) диапазонында булышлык итү, көчәнмичә, башкаларның барысы белән бер темпта җырлау, сүзләрне чиста һәм ачык итеп әйтү, җыр характерын (күңелле, озын, йомшак, аһәңле) чагылдыруга булышлык итү.

*Җыр иҗаты*. «Әлли-бәлли» иҗекле бишек җырларының, «лә-лә» иҗекле күңелле җыр көйләренең ахырын җырлап бетерергә өйрәтү. Үрнәк буенча күңелле һәм моңлы җырлар иҗат итү күнекмәләрен формалаштыру.

*Музыкаль-ритмик хәрәкәтләр*. Музыканың ике өлешле формасына һәм аның яңгырау көченә (көчле, акрын) тәңгәл рәвештә хәрәкәт итәргә; музыка яңгырый башлауны һәм аның тәмамлануын тоюны белдерергә өйрәнү.

Төп хәрәкәтләр (йөрү һәм йөгерү) күнекмәләрен камилләштерү. Башкалар белән бергә һәм ялгыз гына атлап йөрергә, музыка астында җиңел, салмак һәм тиз темпта йөгерергә өйрәтү.

Бию хәрәкәтләрен башкару сыйфатын яхшырту: чиратлаштырып, ике аяк һәм бер аяк белән тыпырдау.

Парлап бөтерелү, туры галоп башкару, музыкаль әсәрнең темпына һәм ритмына карап, предметлар, уенчыклар белән һәм алардан башка музыка астында хәрәкәтләнә белү күнекмәләрен үстерү.

Уен һәм әкият образларын тәэсирле һәм эмоциональ чагылдыруны үстерүгә булышлык итү: аю килә, песи яшеренеп бара, тычкан балалары йөгерешә, куян сикерә-сикерә бара, әтәч йөри, чебиләр бөртекләр чүплиләр, кошчыклар очалар һ.б.

*Бию-уен иҗаты.* Бию көйләре астында бию хәрәкәтләрен мөстәкыйль башкаруны стимуллаштыру. Сурәтләнүче хайваннарның холкын чагылдыручы хәрәкәтләрне төгәлрәк башкарырга өйрәтү.

*Балалар музыка уен коралларында уйнау*. Балаларны кайбер балалар музыка уен кораллары — сыбызгы, металлофон, кыңгырау, шөлдерле барабан, шалтыравык, барабан, шулай ук аларның яңгырашы белән таныштыру.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны балалар бәрмә музыка уен коралларында уйнарга өйрәтү

***Тәкъдим ителгән музыкаль әсәрләр***

*Музыка тыңлау*

“Әпипә”, татар халык көе, Ю.Виноградов эшкәрт.; “Көз”, Р.Еникеева муз., К.Нәҗми сүзләре; “Көзге яңгыр”, Р.Латыйпов муз., Л.Лерон суз.; “Марш”, И.Шәмсетдинов муз.; “Сүзсез җыр”,татар халык көе, А.Вәлиуллин эшкәрт.; “Песи”, М.Мозаффаров муз., Ә.Ерикәй суз.; “шаян кыз”, Н.җиһанов муз.; “Усал малай” ,Р.Зарипов муз.;”Кыш бабай җыры”, Л.Шиһабетдинов муз., Г.Зәйнашева суз.; “Курчаклар маршы”, Р.Еникеев муз.; “Буран”, М.Мозаффаров муз., Ә.Ерикәй суз.; “Бию” ,А.Вәлиуллин муз.; “Өммегөлсем”,татар халык көе,Ф.Фәизова эшкәрт.; “Яз”, Р.Ахиярова муз.,Г.Рахманколый суз.;”Куян биюе”,”Аю”, Р.Еникеев муз.; “Яңгыр”, Л.Хисмәтуллина муз.; “Үҗәтлек”, Р.Еникеев муз.; “Шук малай”,Ә.Шәрәфиев муз.; “Ат булып уйнау”,Х.Әхмәтов муз.; “Марш”, А.Монасыйпов муз.; “Тамчылар бии”, А.Батыршин муз.,З.Нури сүз.; “Карлыгач”, Р.Еникеева муз., Г.Тукай суз.; “Бишек җыры”, З.Хәбибуллин муз.; “Ялгыз бию”, татар халык көе, А.Ключарев эшкәрт.; “Каз бәбкәләре”, Ә.Бакиров муз.,Ә.Бикчәнтәева сүз.; “Бал корты”, И.Шәмсетдинов муз., Ж.Тәрҗеманов сүз.; “Прогулка”, В.Волков муз., “Дождик”, Н.Любасарский муз.; “Грустный дождик”, Д.Кабалевскии муз.; “Плясовая”,рус халык көе; “Пляска Петрушки”, М.Раухвергер муз.; “Капризуля”,В.Волков муз.; “Солдатскии марш”, Р.Шауман муз.; “Колыбельная”, Т.Назаров муз.; “Баю баю”, М.красев муз., М Чарная сүз.

*Җырлау.*

Музыкаль ишетү һәм тавыш үстерү күнегүләре: “Чәбәк -чәбәк”, Р. Гатина, Ф. Батыршинамузыкасы һәм сүзләре; “Сәгать”, Г.Гыйләҗетдинова музыкасы һәм сүздәре; “Су”, Ф. Җәләлетдинова мызыкасы , Б.Рәхмәт сүзләре; “Дәү әнигә” Н.Мөхетдинова музыкасы, Р.Вәлиева сүзләре; “Яңгыр яу” балалар фольлорыннан, Н.Бакиеваэшкәртмәсе; “Кояш чык” балалар фольлорыннан, Р.Зарипов эшкәртмәсе; “Әлли –бәлли бәү”, Ф.Җәләлетдинова музыкасы, татар халык сүзләре; “Кәккүк”, Н.Бакиева, З.шәйхетдинова музыкасы һәм сүзләре.

*Җырлар:* **“**Тату бармаклар**”,**Ф.Җәләлетдинова музыкасы, татар халык сүзләре; “Бәйрәмгә барабыз”, Г,Гыйләҗетдинова музыкасы, Н.Бакиева, З.Шәйхетдинова сүзләре; “Тек –тек”, Т.Вафина музыкасы, Г.Вафина сүзләре; “Кйз килде”, Л.Шиһабетдинова музыкасы, Ә.Ерикәй сүзләре; “Ап – ак карлар ”,Г.Гәрәева музыкасы һәм сүзләре; “Чыршыкай”, М.Бикбова музыкасы һәм сүзләре; “ Әнием” Ф.Җәләлетдинова музыкасы, Р.Гыйләҗева сүзләре; “Әбекәй”, Т.Вафина музыкасы, татар халык сүзләре; “Яз килә”, Т.Вафина музыкасы, татар халык сүзләре; “Йоклыйсым килә”, М.Шәмсетдинова сүзләре, Ш.Җиһангирова сүзләре; “Үзен бик чиста йөртә”, Н.Зарипова музыкасы, Ж.Тәрҗеманов сүзләре; “Чебиләр”, Л.Шиһабетдинова музыкасы, М.Хөсәен сүзләре; “Тукран”, З.Гыйбадулла музыкасы, Р.Хафизова сүзләре; “Җиләкләр”,Р. Еникеева музыкасы, Н.Гайсин сүзләре;

*Җыр иҗаты:* “Исемең ничек?”, Ф.Җәләлетдинова музыкасы; “Әлли - бәлли”, Ф.Җәләлетдинова музыкасы һәм сүзләре; “Тукран”, Н.Бакиева музыкасы, татар халык сүзләре; “Тукран”, Н.Бакиева музыкасы, татар халык сүзләре; “Куян”, Ф.Җәләлетдинова музыкасы һәм сүзләре; “Әтәч”, Ф.Җәләлетдинова музыкасы, Г.Лотфи сүзләре; “Без уйныйбыз”,

Ф.Җәләлетдинова музыкасы, татар халык сүзләре; “Урманда бәйрәм”, Н.Мөхетдинова музыкасы, Р.Вәлиева сүзләре.

*Музыкаль – ритмик хәрәкәтләр*

Уен күнегүләре: “Чәбәкәй”, Р.Ахиярова музыкасы, Х.Халиков сүзләре; “Йөрибез”, Ф.Шәймәрданова музыкасы; “Күңелле”, А.Монасыйпов музыкасы; “Марш”, Л.Шиһабетдинова музыкасы; “Йөгердек”, А.Монасыйпов музыкасы (этюд); “Куллар өчен күнегү”, Л.Хисмәтуллина музыкасы; “Без бердәм атлыйбыз”, Н.Бакиева , З.Шәйхетдинова музыкасы һәм сүзләре; “Ай матур гөл генә”, татар халык көе, Р. Еникеева эшкәртмәсе; “Баскычтан баскычка”, Р. Еникеева музыкасы; “Бию”, Җ.Фәйзи музыкасы; “Атта”, Ф.Әхмәтов музыкасы; “Марш”,Ә.Шәрәфиев музыкасы; “Кошлар оча”, И.Сафин музыкасы; “Чәчәкләр белән күнегү”,Л.Шаһабетдинова музыкасы; “Паровоз”, Р.Ахиярова музыкасы; “Ладушки”, Н.Римский – Корсаков музыкасы; “Пружинка”, рус халык көе, Т.Ломова эшкәртмәсе; “Марш и бег”, Ан.Александров музыкасы; “Лошадка”, М.Симанский музыкасы; “Сапожки”, рус халык көе, Т.Ломова эшкәртмәсе;

Этюд – драматизацияләр: “Самолет”, Р.Зарипов музыкасы; “Куяннар һәм төлке”, Ф.Шәймәрданов музыкасы; “Күк күгәрчен”, татар халык көе, М Мозаффаров эшкәртмәсе; “Аю баласы”, Ә. Шәрәфиев музыкасы; “Мәче балалары”, Р .Зарипов музыкасы; “Чыпчыклар”, Ф.Шәймәрданов музыкасы; “Чебиләр зарядкасы”, Л.Хәйретдинова музыкасы, М.Фәйзуллина сүзләре; “Птички летают”, А.Серов музыкасы; “Мышки”, Н.Сушен музыкасы.

Уеннар: “Аю баласы”, Ф.Әбүбәкеров музыкасы, Н.Исәнбәт сүзләре; “Яңгыр”, Р.Гатина, Ф.Батыршина музыкасы һәм сүзләре, Г.Гыйләҗетдинова эшкәртмәсе; “Туп - тубыбыз”, Л.Шиһабетдинова музыкасы, Ә.Бикчәнтәева сүзләре; “Качышлы”, татар халык көе, Ф.Җәләлетдинова эшкәртмәсе; “Кар бөртекләре”, Р.Гатина, Ф.Батыршина музыкасы һәм сүзләре, Г.Гыйләҗетдинова эшкәртмәсе; “Бу куянга ни булган?”, Л.Хисмәтуллина музыкасы, татар халык сүзләре; “Качышлы уены”, В.Вәлиева музыкасы һәм сүзләре; “Курчак белән уен”, Ф.Шәймәрданов музыкасы; “Песи һәм чыпчыклар”, М.Әндерҗанова музыкасы һәм сүзләре; “Аткаем”, “Карусель”, Р.Гатина, Ф.Батыршина музыкасы һәм сүзләре, Г.Гыйләҗетдинова эшкәртмәсе; “Бөҗәкләр”, Т.Вафина музыкасы, Г.Вафина сүзләре; “Игра с погремушками”,рус халык көе, А. Быкнов эшкәртмәсе; “Кошка и котята”, В.Витлин музыкасы; “Ловишки”, Й.Гайдн музыкасы; “Солнышко и дождик”, М.Раухвергер музыкасы, А.Барто сүзләре.

### 2.1.5 «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе

«Физик үсеш балалар эшчәнлегенең түбәндәге төрләрендә тәҗрибә булдыруны үз эченә ала: хәрәкәтләнү, шул исәптән координация һәм сыгылмалылык кебек физик сыйфатларны үстерүгә юнәлтелгән, организмның терәкхәрәкәт системасын дөрес формалаштыруга, тигезлек саклауга, хәрәкәтне координацияләүгә, кулларның эре һәм вак моторикасына булышлык итүче, шулай ук төп хәрәкәтләре дөрес һәм организмга зыян салмаслык итеп башкарылган атлап йөрү, йөгерү, җиңелчә сикерүләр, ике якка да борылулар кебек күнегүләрне эшләү белән бәйле хәрәкәт эшчәнлеге; спортның кайбер төрләре турында башлангыч күзаллаулар формалашу; кагыйдәләре белән бергә хәрәкәтчел уеннарны үзләштерү; хәрәкәтләнү өлкәсендә максатчанлык һәм үз-үзеңне көйләү формалашу; сәламәт яшәү рәвеше кыймматләре формалашу, шул яшәү рәвешенең элементар нормаларын һәм кагыйдәләрен үзләштерү (туклануда, хәрәкәтләнү режимында, чыныгуда, файдалы гадәтләр формалаштыруда һ.б.»

***Төп максатлар һәм бурычлар:***

*Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру*. Балаларда сәламәт яшәү турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру.

*Физик культура.* Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту; акыл һәм физик мөмкинлекләрен арттыру, талчыгуны искәртү.

Гармонияле физик үсешне тәэмин итү, төп хәрәкәт төрләрендә сәләт һәм күнекмәләрне камилләштерү, хәрәкәтләрнең матурлыгына, нәзакәтлелегенә, тәэсирлелегенә ирешү, гәүдәнең дөрес тотышын формалаштыру.

Көндәлек хәрәкәтләнү эшчәнлеге ихтыяҗы формалаштыру. Хәрәкәтләнү эшчәнлегендә инициативалылык, мөстәкыйльлек һәм иҗат, үз-үзеңне контрольдә тоту, хәрәкәтләр башкарганда үз-үзеңне бәяләү сыйфатларын үстерү.

Хәрәкәтле уеннарда һәм спорт уеннарында, физик күнегүләрдә катнашуга карата кызыксынуны, мөстәкыйль хәрәкәтләнү эшчәнлегендә активлыкны үстерү; спортка карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

## 2.2 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының төп белем бирү программасын гамәлгә ашыру формалары, ысуллары, алымнары һәм чаралары

Үсешкә китерүче һәм бала өчен эмоциональ яктан уңайлы белем бирү мохите тудыру «Туганнан алып мәктәпкәчә» программасын гамәлгә ашыруның иң мөһим шарты булып тора. Балалар бакчасында булу балага шатлык китерергә, ә белем бирү ситуацияләре мавыктыргыч булырга тиеш.

Иң мөһим белем бирү ориентирлары:

• балаларның эмоциональ иминлеген тәэмин итү;

• балаларның башка кешеләргә карата дустанә һәм игътибарлы мөнәсәбәтен формалаштыру өчен шартлар тудыру;

• балалар мөстәкыйльлеген (инициативалылыкны, автономия һәм җаваплылыкны) үстерү;

• балаларның эшчәнлекнең төрле төрләрендә формалашучы сәләтләрен үстерү. Әлеге максатларны гамәлгә ашыру өчен педагогларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

• бала шәхесенә карата ихтирам күрсәтү, аның белән һәм башка педагоглар белән үзара мөнәсәбәтләрнең демократик стилен үстерү;

• баланың үз өстенә җаваплылык алу һәм башка кешеләргә карата үз итү хисләрен белдерү өчен шартлар тудыру;

• килеп туган низагларны балалар белән бергә тикшерү, аларны хәл итәргә булышу, гомуми кагыйдәләр булдыру, бер-береңә карата ихтирам күрсәтергә өйрәтү;

• балалар белән тормышның мөһим мәсьәләләрен тикшерү, баланың үз позициясен белдерүен стимуллаштыру;

• балаларның игътибарын кешеләрнең үз карашлары һәм кыйммәтләре буенча бер-берсеннән аерылып торуларына юнәлтү, моның аларның үзүзләрен тотышына ничек йогынты ясавын тикшерү;

• ата-аналар (законлы вәкилләр) белән Оешма педагогларының эшчәнлеге юнәлтелгән, шул эшчәнлек ирешергә тиешле ориентирларны тикшерү, гаилә әгъзаларын әлеге максатларга ирешү буенча бергәләп эш итүгә тарту.

Мәгариф оешмасында мәктәпкәчә белем бирү системасы баланың уены һәм танып белү активлыгы үсешенә төбәлгән булырга тиеш. Оешмада инициативалылык, күңел күтәренкелеге, кызыксынучанлык һәм яңаны белү омтылышы кебек сыйфатлар чагылсын өчен шартлар тудырылырга тиеш.

Белем бирү мохитен дөрес оештыру үз-үзеңә ышаныч, тормышка карата оптимистик караш үсешен стимуллаштыра, ялгышуга хокук бирә, танып белү мәнфәгатьләрен формалаштыра, хезмәттәшлек итәргә әзер булуны һәм башка кешегә авыр хәлдә ярдәм итүне хуплый, ягъни баланың уңышлы рәвештә социальләшүен һәм аның шәхесе үсешен тәэмин итә.

Балалар тарафыннан өйрәнелүче темалар белем бирү эшенең максатларына — баланың сәләтләрен һәм инициативасын үстерүгә, мәктәпкәчә яшьтәге балага аңлаешлы мәдәни чараларны (күрсәтмә модельләрне һәм символларны) үзләштерүгә ирешү өчен материал булып тора. Шунлыктан белем бирү программасы гомер буе барачак уку-өйрәнү сәләте булдыруны, шул ук вакытта чынбарлыкка карата аңлы һәм иҗади мөнәсәбәттә булуны таләп иткән хәзерге җәмгыятьтә балаларны тормышка әзерләүнең нигезенә әверелә.

Балалар бакчасында балага яхшы таныш көн дә кабатлана торган хәлләр тәрбия-белем бирү әһәмиятенә ия: һавада йөргәндә һәм режим моментлары вакытында бала үзенә һәм башкаларга карата мөнәсәбәтләр булдыра, инициативалы булырга һәм карарлар кабул итәргә, үзенең фикерләвен һәм хыялын файдаланырга өйрәнә..

## 2.3 Балалар бакчасының гаилә белән багланышлары

***Төп максатлар һәм бурычлар***

Гаилә белән конструктив багланышлар үстерү бала шәхесенең тулы үсешен тәэмин итүнең иң мөһим шарты булып тора.

Төп максат — тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы үзара мөнәсәбәтләр формалаштыру һәм ата-аналарның компетентлыгын (бала тәрбияләү белән бәйле төрле типтагы социаль-педагогик ситуацияләрне хәл итә алу сәләтен) үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру; ата-аналарның ихтирамлы һәм аңлаулы мөнәсәбәткә, балалар бакчасы тормышында катнашуга хокукын тәэмин итү.

Ата-аналарга һәм тәрбиячеләргә үзара мөнәсәбәтләрдә субординациядән, монологизмнан арыну, бер-берләрен гаепләү гадәтеннән баш тарту, бер-берләрен үз проблемаларын хәл итү чарасы итеп түгел, ә тигез хокуклы партнерлар, хезмәттәшләр итеп күрә белү зарур.

Балалар бакчасының гаилә белән багланышларының төп бурычлары:

• педагогларның һәм ата-аналарның балаларны тәрбияләү, өйрәтү-укыту, үсешләренә ирешү, балалар бакчасында һәм гаиләдә төрле эшчәнлекне оештыру шартларына кагылышлы төрле мәсьәләләргә карата мөнәсәбәтләрен өйрәтү;

• педагогларны һәм ата-аналарны балалар бакчасында һәм гаиләдә тәрбияләүнең иң отышлы тәҗрибәсе, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә һәм җәмгыятьтә тәрбияләүдә туган кыенлыклар белән таныштыру;

• балаларны тәрбияләүнең һәм өйрәтү-укытуның актуаль мәсьәләләре, балалар бакчасының һәм гаиләнең әлеге мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлекләре турында бер-берләренә җиткереп тору.

• балалар бакчасында педагогларның һәм ата-аналарның балалар белән үзара конструктив тәэсир итешүе үсешенә булышлык итүче, эчтәлеге һәм формасы буенча төрле булган хезмәттәшлеге өчен шартлар тудыру;

• тәрбияләнүчеләрнең гаиләләрен районда (шәһәрдә, өлкәдә, республикада) оештырыла торган, педагоглар белән бергә уздырылучы чараларда катнашуга җәлеп итү;

• баланың төрле омтылышларына һәм ихтыяҗларына карата игътибарлы мөнәсәбәт күрсәткән ата-аналарны хуплау, әлеге ихтыяҗларны гаиләдә канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру.

*Гаилә белән ике арадагы багланышларның төп юнәлешләре һәм формалары*

Балалар бакчасының гаилә белән үзара бәйләнешенең төп максатлары — тәрбия өлкәсендә ата – аналарның хәбәрдарлыгын күтәрү, мәктәпкәчә яшьтәге баланың бөтен шәхси үсешен тәэмин итүче тәрбиячеләрнең гаиләләре белән җаваплы һәм тулы бәйләнештәге тәэсирләренең үсешенә кирәкле булган шартларны балалар бакчасында тудыру.

**Гаилә белән ике арадагы багланышларның төп юнәлешләре һәм формалары**

| | |
|---|---|
| Гаилә белән танышу | Очрашу - танышулар, гаиләнең өенә бару, гаиләләрне анкеталаштыру |
| Белем бирү процессының барышы турында ата –аналарны хәбәрдар итү | Ачык ишекләр көне, аерым һәм төркем консультацияләре, ата – аналар җыелышлары, хәбәр тотучы стендларны бизәү, балалар иҗаты күргәсмәсен оештыру, ата –аналарны балалар концертларына һәм бәйрәмнәренә чакыру, белешмәләр, интернет - журналлар, электрон почта аша язышуны булдыру. |
| Ата – аналарның белемнәре: | организация «Әти–әниләр мәктәбе», «Әти–әниләр өчен мәктәпләр» (лекцияләр, семинарлар, семинар-практикумнар), мастер-класслар, тренинглар үткәрүне, китапханәләр булдыруны оештыу. |
| Бердәм эшчәнлек | Музыка һәм шигърият, конкурслар, якшәмбе гаилә абонементы концертлары, ял көне маршрутлары ( театрга, музейга, китапханә h.б.), гаилә берләшмәләре (клуб, студия, секция), гаилә бәйрәмнәре, һавада булулар, экскурсияләр, гаилә театры, балалар тикшерү һәм проект эшчәнлегендә катнашырга ата–аналарны тарту. |

**Ата-аналар белән эшләү планы**

| *Вакыты* | *Тематикасы* | *Үткәрү алымы* |
|---|---|---|
| **Сентябрь** | 1. «Оештыру җыелышы»<br>2. «3-4 яшьлек баланың яшь үзенчәлекләре».<br>3.Балаларның үз-үзләрен тотышы.<br>4. Туган телне УМК кулланып өйрәнәбез | Ата –аналар җыелышы.<br>Папка–ширма.<br>Консультация.<br>Папка–ширма. |

| | | |
|---|---|---|
| **Октябрь** | 1. Балалар бакчасыннан соң киеренкелекне ничек бетерергә?<br>2. Нәрсә ул сенсорика һәм моторика?Аның үсеше нигә кирәк?<br>3. Балаларны ничек рәсем ясарга өйрәтергә?.<br>4. Уйный-уйный өйрәнәбез. | Папка–ширма.<br><br>Әңгәмә.<br>Консультация.<br>Консультация. |
| **Ноябрь** | 1. Дөрес туклану балалар өчен сәламәтлек нигезе.<br>2. Сезнең балагызның характеры.<br>3. Татар халык авыз иҗаты<br>4. 4 нче яшьтәге балаларның гигиеник һәм үз–үзенә хезмәт күрсәтү алымнары.. | Консультация.<br>Папка–ширма.<br>Анкеталаштыру.<br>Белешмә.<br>Консультация. |
| **Декабрь** | 1. 3-4 яшьлек балаларның кирелеге, көйсезлеге.<br>2. Бармак уеннары .<br>3. Баланың сәламәтлеккә юлы гаилә аша бара.<br>4. Балалар бакчасы һәм гаилә бердәм булса | Ата –аналар җыелышы.<br>Папка–ширма.<br>Консультация.<br>Папка–ширма |
| **Январь** | 1. Куркынычсызлык кагыйдәләре.<br>2. 3–4 яшьлек баланың сөйләм үсеше үзенчәлекләре.<br>3. Балаларга – витаминнар. | Әңгәмә.<br>Консультация.<br>Папка - ширма. |
| **Февраль** | 1. Тәрбияле бала җанга – шатлык, йөзгә аклык китерә.<br>2. Эш яратып үссеннәр.<br>3. Балаларга нинди уенчыклар кирәк.<br>4. Сәламәт яшәү рәвеше. | Белешмә.<br>Папка-ширма.<br>Консультация.<br>Папка-ширма. |
| **Март** | 1. Гаилә һәм балалар бакчасы хезмәттәшлегендә актуаль проблемалар.<br>2. Яратырга өйрәник<br>3. Физик үсеш турында.<br>4. Баланы саф һавага ничек киендерергә? | Әңгәмә.<br>Киңәшләр<br>Белешмә.<br>Папка–ширма.<br>Әңгәмә. |
| **Апрель** | 1. Юл әлифбасы.<br>2. Сөйләм үсешенә балалар фольклорын куллану.<br>3. Авырудан саклану чаралары.<br>4. Баланы тыңларга өйрәтик. | Папка–ширма.<br>Папка-ширма.<br>Папка–ширма.<br>Әңгәмә. |
| **Май** | 1. Безнең уңышларыбыз,нәтиҗәләр<br>2. Балаларның чыныгуы.<br>3.Үстерешле уеннар. | Ата – аналар җыелышы.<br>Консультация.<br>Папка–ширма. |

**Балалар һәм ата-аналар берлектә эш**

| *№* | *Үткәреләчәк чара* | *Вакыты* | *Җаваплы* |
|---|---|---|---|
| <br>1<br>2 | ***Мастер класс***<br>«Тылсымлы куллар»<br>«Учимся - играя» | <br>декабрь (ата-аналар җыелышы)<br>май (ата-аналар җыелышы) | Мингулова А.Ш.<br>Сибгатуллина Р.М. |
| 1 | ***Фотовыставка*** «Минем гаиләм» | декабрь | |
| | ***Смотр-конкурс*** «Әниемнең алтын куллары» | январь | |

## 2.4. Төп юнәлешләр буенча перспектив планлаштыру

### 2.4.1 Юлларда хәвеф - хәтәрсез йөрү кагыйдәләрен тәрбияләү

| № | *Үткәреләчәк чара* | *Вакыты* | *Җаваплы* |
|---|---|---|---|
| 1 | ***Күңел ачулар:***<br>1. Курчак театры «Урманда булган хәл».<br>2. «Юлда уйнамагыз!»<br>*Используемая литература:*<br>Старцева О.Ю. Школа дорожных наук: Профилактика | <br>Декабрь<br>Апрель | Сибгатуллина Р.М.<br>Мингулова А.Ш. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | детского дорожно-транспортного травматизма.- М.: ТЦ Сфера, 2008, стр 30. | | |
| 2 | ***Экскурсиялар:***<br>1. «Урам белән танышабыз».<br>2. «Светофор янына экскурсия».<br>*Используемая литература:*<br>Старцева О.Ю. Школа дорожных наук: Профилактика детского дорожно-транспортного травматизма.- М.: ТЦ Сфера, 2008, стр 57-58. | Октябрь<br>Апрель | Сибгатуллина Р.М.<br>Мингулова А.Ш. |
| 3 | ***Күзәтүләр:***<br>1. Шәһәр транспортын күзәтү.<br>2. Автобусны күзәтү.<br>3. Йөк һәм җиңел автомобильләрне күзәтү һәм чагыштыру.<br>4. Автотранспорт йөртүчесен күзәтү.<br>5. Тротуарда җәяүлеләр хәрәкәтен күзәтү.<br>6. Светофор эшен күзәтү.<br>7. Тукталышта пассажирларныкүзәтү.<br>8. ГАИ хезмәткәренең эшен күзәтү.<br>9. Җәяүлеләр хәрәкәтен күзәтү.<br>*Используемая литература:*<br>Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах: учеб.пособие/ авт.-сост.: Р.Ш.Ахмадиева, Е.Е.Воронина, Р.Н.минниханов и др.- Издание ГУ «НЦ БЖД», 2008, стр 228. | Сентябрь<br>Октябрь<br>Ноябрь<br>Декабрь<br>Январь<br>Февраль<br>Март<br>Апрель<br>Май | Сибгатуллина Р.М.<br>Мингулова А.Ш. |
| 4 | ***Сюжетлы-үстерешле уеннар:***<br>1) «Кызыл, сары, яшел» (стр.11).<br>2) «Ватылган светофор».<br>3) «Әйберләрнең төсләре һәм формалары».<br>4) «Сигналлар һәм хәрәкәт. Кирәк юнәлештә йөреш» (стр. 14).<br>5) «Транспорт төрләре».<br>6) «Автобус» (стр. 10).<br>7) «Йөк һәм җиңел автомобиль».<br>8) «Безнең шәһәр урамнары» (стр.15).<br>*Используемая литература:*<br>1. Старцева О.Ю. Школа дорожных наук: Профилактика детского дорожно-транспортного травматизма.- М.: ТЦ Сфера, 2008,стр 53-58.<br>2. Обучение детей дошкольного возраста правилам безопасного поведения на дорогах. Учебный план и программы обучения детей правилам безопасного поведения на дорогах в дошкольных образовательных учреждениях.<br>3. «Дошкольникам о правилах дорожного движения» Степанкова, Филенко.<br>«Учебный план и программа обучения детей правилам безопасности поведения на дорогах». | Октябрь<br>Ноябрь<br>Декабрь<br>Январь<br>Февраль<br>Март<br>Апрель<br>Май | Сибгатуллина Р.М.<br>Мингулова А.Ш. |
| 5 | ***Ата-аналарга консультациялар:***<br>1. «Игътибар! Юл!»<br>2. «Урам аша чыгу кагыйдәләре» | Октябрь<br>Март | Сибгатуллина Р.М.<br>Мингулова А.Ш. |

### 2.4.2 Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру

| № | *Үткәреләчәк чара* | *Вакыты* | *Җаваплы* |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ***Күңел ачулар:*** | | |
| 1 | «Су, су, минем битемне ю». | октябрь | |
| 2 | «Гөмбәләр белән танышабыз». | февраль | |
| | ***ОБЖ буенча эшчәнлек:*** | | |
| 1 | «Светофорга булышабыз» (дид. игра). | сентябрь | |
| 2 | «Шырпы уенчык түгел» (занятие). | ноябрь | |
| 3 | «Табышмаклар-җаваплар» (дид. игра). | декабрь | |
| 4 | «Зарядка нигә кирәк» (занятие). | январь | |
| 5 | «Янгын куркынычы кагыйдәләре турында» (дид. игра). | март | |
| 6 | «Күзләребез яхшы күрсен» (занятие). | апрель | Сибгатуллина Р.М. |
| 7 | «Эт һәм мәче - безнең дуслар» (занятие). | май | Мингулова А.Ш. |
| | ***Ата-аналарга консультацияләр:*** | | |
| 1 | «Балаларның тәртипсезлеге аркасында килеп чыккан имгәнүләр» | сентябрь | |
| 2 | «Күңелсез хәлләрне булдырмау». | ноябрь | |
| 3 | «Әти-әниләр игътибарлы булыгыз». | февраль | |
| 4 | «Өйдә һәм тышта шәхси куркынычсызлык». | май | |

**2.4.3 Физкультура-сәламәтләндерү эшчәнлеге**

| № | *Үткәреләчәк чара* | *Вакыты* | *Җаваплы* |
|---|---|---|---|
| | ***Физкультурный досуг:*** | | |
| 1 | «Күңелле куяннар» | сентябрь | Сибгатуллина Р.М. |
| 2 | «Айболит киңәшләре» | октябрь | Мингулова А.Ш. |
| 3 | «Мишкага кунакка» | ноябрь | |
| 4 | «Күңелле аюлар» | декабрь | |
| 5 | «Кышкы әкият иленә сәяхәт» | январь | |
| 6 | «Кар бабай белән очрашу» | февраль | |
| 7 | «Язгы урманга сәяхәт» | март | |
| 8 | «Сәламәт булыгыз!» | апрель | |
| 9 | «Кояшка кунакка» | май | |
| | ***Спортивные праздники:*** | | |
| 1 | «Кояш һәм яңгыр» | июнь | Сибгатуллина Р.М. |
| 2 | «Салкын кыш» | февраль | Мингулова А.Ш. |

## 2.5 Белем өлкәләре буенча календарь-тематик планлаштыру

### 2.5.1 «Элементар математик күзаллауны формалаштыру» буенча перспектив планлаштыру

Л.Г.Петерсон, Е.Е. Кочемасова. Игралочка. Просвещение/Бином, 2021.

| № | Занятие темасы | Максат ориентирлары | Сылтама |
|---|---|---|---|
| | | **СЕНТЯБРЬ** | |
| 1 | “Бер”, “күп” төшенчәләре белән таныштыру | Төркемнән әйберләрне аерып алырга, әйберләрдән төркем төзергә өйрәтү. Балаларның фантазияләрен үстерү, кызыксыну тәрбияләү. | *9 бит, зан. №1.* |
| 2 | “Әйберләрне чагыштыру. Шуның кадәр” | Парлаштыру юлы белән әйберләрне чагыштырырга өйрәтү. “Бер”, “күп” аңлатмасын ныгыту. Балаларның фантазияләрен, сәләтләрен баету. | *10 бит, зан. № 2.* |
| 3 | “Әйберләрне чагыштыру. Шуның кадәр” | Парлаштыру юлы белән әйберләрне чагыштырырга өйрәтү. “Бер”, “күп” аңлатмасын ныгыту. Балаларның фантазияләрен, сәләтләрен баету. | *10 бит, зан. № 2* |
| 4 | “Шуның кадәр. Күбрәк, әзрәк” | Әйберләрнең санын парлаштыру юлы белән чагыштыру (шуның кадәр, күбрәк, әзрәк). Санны үзгәртмәскә кирәклеген аңлату. Күзәтүчәнлек, игътибарлылык | *12 бит, зан. № 3.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тәрбияләү. | |
| **ОКТЯБРЬ** | | | |
| 1 | “Шуның кадәр. Күбрәк, әзрәк” | “Бер”, “күп” аңлатмалары өстендә эшләү. Парлаштырып чагыштыруны ныгыту. Әйберләрнең охшаш һәм аерым якларын аерырга өйрәтү. Балаларны бер-берсе белән аралашырга өйрәтү. | *13 бит, зан. № 4.* |
| 2 | “Шуның кадәр. Күбрәк, әзрәк” | Чагыштыру алымын, “бер”, “күп” төшенчәләрен ныгыту. Төсләр белән билгеләнгән күплекләрне күрергә өйрәтү. Фигураларның урнашу закончалыкларын күререгә өйрәтү. | *15 бит, зан. № .5* |
| 3 | “Әйберләрнең үзлекләре. Икегә кадәр санау” | Әйберләрнең үзлекләре белән таныштыра башлау. Икегә кадәр санарга өйрәтү. Арттыру һәм кәметү юлын аңлату, тигезлекнең килеп чыгуын күрсәтү. Фикер йөртергә, вакытны күзаллауны, сөйләм телен үстерү. | *16 бит, зан. № 6.* |
| 4 | “Әйберләрнең үзлекләре. Икегә кадәр санау” | Әйберләрнең үзлекләре белән таныштыра башлау. Икегә кадәр санарга өйрәтү. Арттыру һәм кәметү юлын аңлату, тигезлекнең килеп чыгуын күрсәтү. Фикер йөртергә, вакытны күзаллауны, сөйләм телен үстерү. | *16 бит, зан. № 6.* |
| **НОЯБРЬ** | | | |
| 1 | “Икегә кадәр санау”. 1 һәм 2 цифрлары | Икегә кадәр санауны ныгыту. 1 һәм 2 цифрлары белән таныштыру. Әйберләр белән цифрларны туры китерергә өйрәтү. Сөйләм телен, фантазияләрен баету. | *18 бит, зан. № 7.* |
| 2 | “Икегә кадәр санау”. 1 һәм 2 цифрлары | Икегә кадәр санауны ныгыту. 1 һәм 2 цифрлары белән таныштыру. Әйберләр белән цифрларны туры китерергә өйрәтү. Сөйләм телен, фантазияләрен баету. | *18 бит, зан. № 7.* |
| 3 | “Озынрак, кыскарак” | “Озынрак, кыскарак” сүзләренең мәгънәсен аңлату, чагыштырырга өйрәтү. 1-2 гә кадәр санауны ныгыту. Пространство күзаллауларын үстерү. | *21 бит, зан. № 8.* |
| 4 | “Түгәрәк” | Түгәрәк һәм аның үзлекләре белән таныштыру. Икегә кадәр санауны ныгыту. Әйберләрне 1-2 саны белән туры китерү, “уң якка”, “сул якка” төшенчәләрен ныгыту. | *21 бит, зан. № 9.* |
| **ДЕКАБРЬ** | | | |
| 1 | “Шар” | Шар, аның үзлекләре белән таныштыру, икегә кадәр санауны ныгыту. Әйберләрне 1-2 саны белән туры китерү, “уң якка”, “сул якка” төшенчәләрен ныгыту. Фикер йөртү сәләтләрен үстерү. | *24 бит, зан. №10.* |
| 2 | “Киңрәк, таррак” | Ике әйберне чагыштырырга һәм “киңрәк”, “таррак” сүзләрен кулланырга өйрәтү, охшаш һәм аерым үзлекләрен табарга һәм дөрес әйтергә өйрәтү. Икегә кадәр санауны ныгыту. Иҗади фикерләүләрен үстерү. | *26 бит, зан. №11.* |
| 3 | “Киңрәк, таррак” | Ике әйберне чагыштырырга һәм “киңрәк”, “таррак” сүзләрен кулланырга өйрәтү, охшаш һәм аерым үзлекләрен табарга һәм дөрес әйтергә өйрәтү. Икегә кадәр санауны ныгыту. Иҗади фикерләүләрен үстерү. | *26 бит, зан. №11.* |
| 4 | “3 кә кадәр санау. 3 саны” | 3 санының килеп чыгуын аңлату, 3 кә кадәр санарга өйрәтү. Өчпочмак белән таныштыру. Иҗади сәләтләрен үстерү. | *28 бит, зан. № 12.* |
| **ЯНВАРЬ** | | | |
| 1 | “3 цифрасы” | 3 цифрасы белән таныштыру. 1-3 саннарын әйберләр белән туры китерү. Геометрик фигуралар турында | *31 бит, зан. № 13.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | белемнәрен ныгыту.Чагыштырырга, фикерләрен анализларга өйрәтү. | |
| 2 | “Өстендә, астында” | “Өстендә”, “ астында”, “янында” сүзләренең мәгънәләрен аңлату. 3 кә кадәр санауны ныгыту. 3 әйберне чагыштыру. Үзлектән эшләргә өйрәтү, фикер йөртү сәләтен үстерү. | *32 бит, зан. № 14.* |
| 3 | “Биек. Түбән” | Биеклекне чагыштырырга өйрәтү. 3 кә кадәр санауны ныгыту. Күзәтүчәнлек, игътибарлылык тәрбияләү. | *34 бит, зан. № 15.* |
| **ФЕВРАЛЬ** | | | |
| 1 | “Иртәрәк, соңрак” | Вакыт күзаллауларын формалаштыру. Санауны ныгыту (1-3 саннары). Логик фикерләүне, хәтерләрен, игътибарлылыкны үстерү. Кызыксыну тәрбияләү. | *36 бит, зан. № 16.* |
| 2 | “4 кә кадәр санау. 4 саны, 4 цифрасы” | 4 саны, 4 цифрасы белән таныштыру. 3 һәм 4 әйберне чагыштыру. Әйберләрнең үзлекләренә характеристика бирү. Күзәтүчәнлек, сөйләм телен үстерү. | *37 бит, зан. № 17.* |
| 3 | “Квадрат” | Квадрат белән таныштыру. 4 кә кадәр санауны ныгыту. Әйберләрнең охшаш, аерым якларын табып чагыштыру. | *39 бит, зан. № 18.* |
| 4 | “Куб” | Куб һәм аның үзлекләре белән таныштыру. 4 кә кадәр санауны ныгыту. Вакыт төшенчәсен камилләштерү. Әйберләрнең үзлекләрен табып әйтергә өйрәтү. | *41 бит, зан. № 19.* |
| **МАРТ** | | | |
| 1 | “Аста , өстә” | “Аста”, “ өстә” төшенчәләрен камилләштерү. Геометрик фигуралар турында белемнәрен ныгыту. Әйберләрнең охшаш, аерым якларын табарга өйрәтүне дәвам итү. Фикер йөртү осталыгын үстерү. | *43 бит, зан. № 20.* |
| 2 | “Уңда, сулда, уртада” | Вакыт һәм пространство төшенчәләрен формалаштыру. 1-4 саннары, геометрик фигуралар турында белемнәрен ныгыту. Охшаш, аерым якларны табарга өйрәтүне дәвам итү. Игътибарлылык тәрбияләү. | *45 бит, зан. № 21.* |
| 3 | “5 кә кадәр санау. 5 саны. 5 цифрасы” | 5 санының ничек барлыкка килүен аңлату. 5 саны, аның язылышы белән таныштыру. Вакыт төшенчәсен камилләштерү. Фикер йөртү сәләтләрен үстерү. | *47 бит, зан. № 22.* |
| 4 | “Эчтә, тышта” | “Эчтә”, “тышта” төшенчәләрен аңлату. 1-5 саны белән әйберләрне туры китерүне ныгыту, рәтләр төзү күнекмәләре бирү. Капшап карау юлы белән санарга өйрәтү. | *49 бит, зан. № 23.* |
| **АПРЕЛЬ** | | | |
| 1 | “Алда, артта, арада” | “Алда”, “артта”, “арада” төшенчәләрен аңлату. 5 кә кадәр санауны, 5 санын тануны ныгыту. Сөйләм телен, иҗади фикер йөртү сәләтен, хәтерләрен үстерү. | *51 бит, зан. № 24.* |
| 2 | “Парлы” | Парлы әйберләр турында күзаллауларын формалаштыру. Әйберләрне озынлыгы, киңлеге, биеклеге буенча чагыштыру. 1-5 кә кадәр санауны ныгыту. | *53 бит, зан. № 25.* |
| 3 | “Овал” | Овал, аның үзлекләре белән таныштыру. Тирә-яктагы әйберләрдә геометрик фигураларны табарга өйрәтү. Санарга һәм саннарны әйберләр белән туры китерүне күнектерү. | *55 бит, зан. № 26.* |
| 4 | “Турыпочмаклык” | Турыпочмаклык, аның үзлекләре белән таныштыру. Геометрик фигураларны танырга өйрәтү. 5 кә кадәр санауны, саннарны тануны ныгыту. | *57 бит, зан. № 27.* |
| **МАЙ** | | | |
| 1 | “Санлы рәт” | Саннар рәтен төзергә өйрәтү. Пространствода ориентлашуны ныгыту. Чагыштыру юлы белән фигураларны төзергә өйрәтү. Үрнәккә карап эшләүне | *59 бит, зан. № 28.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күнектерү. | |
| 2 | “Тәртип саны” | Тәртип саны белән таныштыру. Капшап санауны күнектерү. Акыл үсешләрен, сөйләм телен баету. Үзлектән эшләүне үстерү. | *61бит, зан. № 29.* |
| 3 | “Уен-сәяхәт” | “Уен-сәяхәт”<br>Алда алынган белемнәрен кабатлау. Геометрик фигураларны, 1-5 саннарын, цифраларын тану. Вакыт төшенчәсен, пространствода ориентлашуны ныгыту. | *63 бит, зан. № 30.* |
| 4 | “Уен-сәяхәт” | “Уен-сәяхәт”<br>Алда алынган белемнәрен кабатлау. Геометрик фигураларны, 1-5 саннарын, цифраларын тану. Вакыт төшенчәсен, пространствода ориентлашуны ныгыту. | *63 бит, зан. № 30.* |

### 2.5.2 Әйләнә-тирә белән таныштыру буенча перспектив планлаштыру
### (Бала һәм әйләнә-тирә)

1. Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И. Җ. Хәбибуллина. Туган телдә сөйләшәбез. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2012

2. Л.А.Парамонова, Развивающие занятия с детьми 3-4 лет. Москва. ОЛМА Медиа Групп. 2013.

| **№** | **Занятие темасы** | **Максат ориентирлары** | **Сылтама** |
|---|---|---|---|
| | | **СЕНТЯБРЬ** | |
| 1 | Кояш, чык! | 1. Җәй турындагы күзаллауларын киңәйтү, тәүлек өлешләрен дөрес әйтергә күнектерү.<br>2. Балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен, күзаллауларын, вак моторикаларын, рәсем ясау күнекмәләрен, иҗади сәләтләрен үстерү.<br>3. Балаларда табигать белән кызыксыну тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 16 бит* |
| 2 | Йомшаккай әзерләгән сюрприз | 1. Агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында агач мате- риалы, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру; тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтү.<br>2. Предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белергә өйрәтү, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерләрен, игътибарларын үстерү.<br>3. Уенчыкларга карата сакчыл караш һәм уеннан соң уенчы- кларны урынына кую гадәте тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 18 бит* |
| 3 | Манара | 1. Балаларны төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге төзү ма- териалы - шакмаклар белән таныштыру, үрнәк буенча манара корылмасы төзергә өйрәтү.<br>2. Предметның төсен, формасын, зурлыгын атый белүләренә ирешү.<br>3. Бергә шөгыльләнү теләге уяту; балалар бакчасына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 22 бит* |
| 4 | Минем яраткан бакчам | “Минем яраткан бакчам”.<br>Тирә-якта ориентлашуны үстерү. Балаларга бакчаны күрсәтү. Һәр бүлмәнең нәрсә өчен кирәклеген аңлату. Керү-чыгу юлларын белү-белмәүләрен тикшерү. | *Парамон. 53 бит* |
| | | **ОКТЯБРЬ** | |
| 1 | “Куян үстергән кишер һәм помидор” | 1. Табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында мәгълүмат бирү, яшелчәләр (кишер, помидор) турында белемнәрен баету.<br>2. Яшелчәләрне (кишер, помидор) тышкы күренеше, тәме, формасы буенча аера белүләренә ирешү; игътибарларын, аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен, сенсорик | *Хәзрәтова, 24 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларда сорауларга җавап бирү теләге уяту; табигатькә уңай караш тәрбияләү | |
| 2 | “Куян үстергән кыяр һәм шалкан” | 1. Балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турында күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, шалкан) турындагы белемнәрен ныгыту.<br>2. Яшелчәләрне (кыяр, шалкан) тышкы күренеше, тәме, фор-масы буенча аера белергә өйрәтүне дәвам итү; игътибарларын, аңга алуларын; диалогик сөйләм, сенсорик сәләтләрен үстерү.<br>3. Сорауларга җавап бирү теләге тудыру; табигать белән кызыксыну тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 28 бит* |
| 3 | “Көз килде” | Балаларны көз фасылы белән таныштыру. Бакчада нәрсәләр өлгергәне турында сөйләшү. Көзнең төп билгеләрен әйтү. | *Парамон. 88 бит* |
| 4 | “Җиләк-җимешләр, яшелчәләр” | Бакчадагы хезмәтнең нәтиҗәсе – җиләк-җимешләр, яшелчәләр турында белем бирү. Таныш җиләк-җимешләрне, яшелчәләрне рәсемнәрдә танып әйтергә өйрәтү. | *Парамон. 108 бит* |
| **НОЯБРЬ** | | | |
| 1 | “Сары, кызыл яфраклар” | 1. Балаларны көз, кыш ел фасылларының характерлы билгеләре белән таныштыру; бер ел вакыты икенчесен ал-маштыруы турында мәгълүмат бирү; көзге яфраклар турында- гы белемнәрен (яфракларның төсләре үзгәрә, алар коелалар) киңәйтү. Авазлар әйтелешен ныгыту.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.<br>3. Көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү; бала- ларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 31 бит* |
| 2 | “Кунак каршылыйб ыз” | 1. Савыт-сабаның аерым предметлары, аларның кулланылы- шы турында белемнәренә төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәнүне дәвам итү; балаларны әңгәмәгә тарту.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын үстерү; тәрбияче биргән сорауны ишетү, аңлау һәм аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү; үз исемен дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү.<br>3. Балаларда сөйләм этикетына нигез салу (исәнләшү, таны- шу, саубуллашу); өлкәннәргә булышу теләге уяту; савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 34 бит* |
| 3 | “Кемнең өе яхшырак?” | Кешеләрнең яши торган урыннары – өйләре турында балаларга белем бирү. Кешеләр белән бергә аларның дуслары – этләре, песиләре дә яшәүләрен аңлату. Урманда яшәүче хайваннарның да өйләре турында әйтү. | *Парамон. 165 бит* |
| 4 | “Курчаклар өчен киемнәр кибете” | Өс, баш, аяк киемнәре турында балаларга белем бирү. Киемнәр турында балаларның күзаллауларын үстерү. Нинди киемне кайчан кияргә кирәклеген аңлату. | *Парамон. 200 бит* |
| **ДЕКАБРЬ** | | | |
| 1 | “Туган ягым - Чистай” | 1. Балаларны туган шәһәребез белән таныштыру, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирү.<br>2. Аңга алуларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү; сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтә белүләренә ирешү, кызыксынуларын үстерү. | *Хәзрәтова, 38 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 3. Туган шәһәр, эшчеләре, аларның хезмәте белән горурлану хисе тәрбияләү. | |
| 2 | “Тылсымлы шкатулка” | 1. Балаларны Яңа ел бәйрәменә әзерлеккә тарту, чыршы уенчыкларының төрләре белән таныштыру, аларны күзәтергә теләк уяту.<br>2. Балаларны чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын атарга өйрәтү; диалогик сөйләмнәрен үстерү, сорауларга җөмлә белән җавап бирергә өйрәтү; аңга алуларын үстерү; берничә сенсорик билгеләре буенча бертөрле предметларны төркемгә берләштерергә өйрәтә башлау.<br>3. Чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү; балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыру- га шартлар тудыру. | *Хәзрәтова, 40 бит* |
| 3 | “Кыш җитте” | Балаларны кыш фасылы белән таныштыру: салкын, кар ява, юллар боз белән капланган, әче җил исә һ.б. Табигатькә карата кызыксыну уяту. | *Парамон. 240 бит* |
| 4 | “Чыршы балаларда кунакта” | Яңа ел каршылауны балаларның тормышына кертү: күңелле бәйрәм шатлыгы тудыру; кыш бабай, кар кызын көтү. Балаларда кызыксыну тәрбияләү. | *Парамон. 297 бит* |
| **ЯНВАРЬ** | | | |
| 1 | “Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз” | 1. Балаларның кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү; тикшеренүләр барышында суның үзлекләре турында мәгълүмат бирү; авазлар артикуляциясен ныгыту.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, танып белү активлыкларын формалаштыру.<br>3. Балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру; кыргый җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 42 бит* |
| 2 | “Чанада шуабыз” рәсемен карау | 1. Балаларны рәсемне карарга, аның эчтәлеген аңларга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү.<br>2. Диалогик сөйләмнәрен, күзәтүчәнлекләрен, күрсәтмә-образлы фикерләүләрен үстерү.<br>3. Кышның матурлыгын күрә белергә өйрәтү. | *Хәзрәтова, 44 бит* |
| 3 | “Петрушка кунакка килде” | Балаларның яңа елда алган хисләрен баету. Әйләнә-тирәдә ориентлашуны киңәйтү. Әйберләрнең сыйфатлары белән таныштыруны дәвам итү. | *Парамон. 315 бит* |
| 4 | “Бу хәл булды январьда...” | Кышкы күңелле хисләрне ныгыту. Яңа ел бәйрәменең өйдә, бакчада ничек үтүен; кыш бабай, кар кызы турында сөйләшү; өйрәнгән шигырьләрне кабатлау. Сәнгатьле сөйләм телен тәрбияләү. | *Парамон. 352 бит* |
| **ФЕВРАЛЬ** | | | |
| 1 | “Җимлек янында” | 1. Кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру; аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү; пумаланың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту.<br>2. Аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү; сүзлек запасын баету; игътибарларын үстерү.<br>3. Күзәтүчәнлек, кошларга карата сак караш, алар турында кайгыртучанлык, кышын аларны тукландыру теләге тәрбияләү | *Хәзрәтова, 46 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | “Ватанны саклаучылар көне” | 1. Балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын; диалогик, монологик сөйләмнәрен үстерү.<br>3. Балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле, кыю бу- лырга омтылыш тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 49 бит* |
| 3 | “Йорт хайваннары” | Йорт хайваннары белән таныштыруны дәвам итү. Аларның кешеләргә ничек файдасы тигәнен аңлату. Хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | *Парамон. 386 бит* |
| 4 | “Кем нәрсә эшли?” | Балаларны һөнәрләр белән таныштыруны дәвам итү; кемнең нәрсә башкарганын аңлату (доктор-дәвалый, дворник-җыештыра, повар-пешерә һ.б.). | *Парамон. 404 бит* |
| **МАРТ** | | | |
| 1 | “Минем әнием” | 1. Әниләр турында әңгәмәдә катнашырга, әниләрнең исемен дөрес әйтә белергә өйрәтү; әзер формалардан бизәк төзеп, кәгазь битендә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү.<br>3. Балаларда әниләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү | *Хәзрәтова, 52 бит* |
| 2 | “Тере һәм уенчык кошларны карау” | 1. Тере һәм уенчык кошларны чагыштыру, уенчык кош - дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту.<br>2. Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү.<br>3. Кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кай- гыртучанлык тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 54 бит* |
| 3 | “Бу кемнең әнисе?” | Йорт хайваннары һәм аларның балалары белән таныштыруны дәвам итү. Фикер йөртү сәләтләрен үстерү, хәтерләрен ныгыту. | *Парамон. 475 бит* |
| 4 | “Безнең китап почмагы” | Китапка карата кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү. Китапның төзелеше белән таныштыру (тышы, эчендә рәсемнәре бар). Китапның тышы буенча әкиятләрне танырга өйрәтү. | *Парамон. 493 бит* |
| **АПРЕЛЬ** | | | |
| 1 | “Урамда яз” | 1. Балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау барышында сүзлек за- пасын киңәйтү һәм активлаштыру.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү.<br>3. Язгы күренешләр белән кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту | *Хәзрәтова, 56 бит* |
| 2 | “Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” рәсемен карау | 1. Балаларны тәрбияче ярдәме белән рәсемнең эчтәлеген аңларга, аның турында сөйләргә, тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү; йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү.<br>2. Балаларның аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, дуслык турындагы күзаллауларын үстерү.<br>3. Хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 58 бит* |
| 3 | “Яз килде” | Яз фасылы белән таныштыру. Табигатьнең матурлыгын күрергә өйрәтү. Яз билгеләрен күрсәтү: кояш җылыта, кар | *Парамон. 511 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | эри, сулар ага һ.б.. | |
| 4 | “Кошлар кайттылар” | Балаларны кошлар белән таныштыру. Яз көне аларның тормышларындагы үзгәрешләре турында аңлату (агачларда оялар ясыйлар, балалар чыгаралар һ.б.). Кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | *Парамон. 549 бит* |
| **МАЙ** | | | |
| 1 | “Йорт хайваннары” рәсемнәрен карау | 1. Балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү.<br>2. Сүзлекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү.<br>3. Йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. | *Хәзрәтова, 58 бит* |
| 2 | “Тузганак чәчәген карау” | 1. Балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) белән таныштыруны дәвам итү.<br>2. Үсемлекне карау барышында әңгәмәгә тарту, хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү.<br>3. Үсемлекләр белән кызыксыну, эстетик хисләр тәрбияләү | *Хәзрәтова, 60 бит* |
| 3 | “Фил кайда яши?” | Әйләнә-тирә белән таныштыруны дәвам итү. Җылы якта яшәүче хайваннар турында белем бирү. Сөйләм телен баету. | *Парамон. 602 бит* |
| 4 | “Суда, күктә, җирдә?” | Транспорт турында балаларның белемнәрен киңәйтү; кайда хәрәкәт итүләрен аңлату. Транспорт исемнәрен ныгыту (поезд, автобус, самолет, пароход һ.б.). | *Парамон. 620 бит* |

### 2.5.3 Сөйләм телен үстерү буенча перспектив планлаштыру

1.Ф.В.Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2012.

2. Л.А.Парамонова, Развивающие занятия с детьми 3-4 лет. Москва. ОЛМА Медиа Групп. 2013.

| № | Занятие темасы | Максат ориентирлары | Сылтама |
|---|---|---|---|
| **СЕНТЯБРЬ** | | | |
| 1 | “Ә” авазы | 1. «Ә» сузык авазын дөрес итеп әйтергә өйрәтергә, авазны кыска һәм озын итеп әйтергә күнектерү. «Ә» авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүне ныгыту.<br>2) Сорауларга җавап бирергә теләк уяту.<br>3) Сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәрбияләү. | *Хәзрәтова 68 бит.* |
| 2 | “Бакчада алмалар өлгерде” | 1. Балаларның көз, табигатьтәге көзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрәтүне дәвам итү.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, сенсорик күнекмәләрен, артикуляция аппаратын үстерү.<br>3. Күмәк эшләүгә тарту, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү | *Хәзрәтова 70 бит.* |
| 3 | “Минем яраткан уенчыкларым” | 1. Төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгы формалаштыру.<br>2. Балаларның предметны исеме, төсе, зурлыгы буенча табу осталыгын, сенсор тоою сәләтен, игътибарын, хәтерен | *Парамон. 16 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үстерү.<br>3. Уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. | |
| 4 | Уенчыклар кибете” | 1. Балаларны предметларның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү; төсне (кызыл, яшел, сары, зәңгәр), зурлыкны (зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк, иң зурысы, иң кечкенәсе) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүз байлыгын арттыру; аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерү<br>2. Игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү.<br>3. Түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү. | *Парамон. 66 бит* |
| **ОКТЯБРЬ** | | | |
| 1 | “Алтын көз” | 1. Тиңдәш кисәкләрдән торган җөмләләр төзергә өйрәтүне; аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда, «бер», «күп», «аз», «берәү дә юк» сүзләрен куллана, сүзләрдә [с], [з], [ф], [к] тартыкларын ачык итеп әйтә белергә өйрәтү.<br>2. Балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын; табигатьнең матурлыгын тоемлауларын, тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирә белүләрен үстерү.<br>3. Табигатькә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | *Хәзрәтова 73 бит.* |
| 2 | “Безнең гаилә” | 1. Балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен баетуны дәвам итү; исемнәрне сан, тартым белән төрләндерүгә (әни-әниләр, әни-әнием) күнектерү.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү.<br>3. Олылар белән иркәле аралашу күнекмәләре; гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү. | *Хәзрәтова 77 бит.* |
| 3 | “Яшелчәләр җыябыз” | Балаларны уенга тарту. “Яшелчәләр” сүзенең мәгънәсен аңлату. <u>О</u> авазының әйтелешен тикшерү, ныгыту. Балаларның сүз байлыгын үстерү. | *Парамон. 84 бит* |
| 4 | “Кәҗә белән сарык” | Балаларны диалогка тарту. <u>Ә</u> авазының әйтелешен тикшерү. Фонематик ишетүне үстерү. | *Парамон. 102 бит* |
| **НОЯБРЬ** | | | |
| 1 | “Алсуның яңа өе” | 1. Балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уенчыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген, сүзлек байлыгын үстерү.<br>3. Тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту, йорт хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. | *Хәзрәтова 79 бит.* |
| 2 | “Уенчык песи баласы турында хикәяләү” | 1. Балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтү; уенчыкны карауга балаларны җәлеп итү; уенчыкны сорауларга җавап бирү юлы белән тасвирларга, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын, күзәтүчәнлеген, сүзлек байлыгын үстерү.<br>3. Тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге уяту, йорт хайваннарына карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык | *Хәзрәтова 82 бит.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хисләре тәрбияләү. | |
| 3 | “Теремкәй тора кырда...” | Балаларны уенга тарту. 2-3 сүзне кушарга өйрәтү. Ы авазының әйтелешен тикшерү, ныгыту. | *Парамон. 122 бит* |
| 4 | “Аю баласы белән” | М авазының әйтелешен өйрәтү. Балаларның ишетү сәләтен үстерү. Кыска сүзтезмә төзергә өйрәтү. | *Парамон. 160 бит* |
| **ДЕКАБРЬ** | | | |
| 1 | “Төлке бездә кунакта” | 1. Сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, «кайда?, «кая?» сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү.<br>2. Игътибарны, тәрбиячененң күрсәтмәләре буенча эшләү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | *Хәзрәтова 85 бит.* |
| 2 | “Алсуны урамга киендерәбез” (Кышкы киемнәрне карау) | 1. Кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, детальләрен, материалын аерып алып, аны карарга өйрәтү, исемне сыйфат белән туры китереп, сорауларга җавап бирүне дәвам итү.<br>2. Тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел (зәңгәр) сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүне, игътибарны, күрү хәтерен үстерү.<br>3. Киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү | *Хәзрәтова 88 бит.* |
| 3 | “Өс киемнәре” | Б авазын тикшерү, әйтелешен ныгыту. Балаларның дикциясен, артикуляцион аппаратын үстерү. Сүзләрнең мәгънәсен аңларга өйрәтү. | *Парамон. 196 бит* |
| 4 | “Аяк киемнәре” | М, Б, П авазларын тикшерү, әйтелешен ныгыту. Балаларны уенга тарту. Аяк киемнәре исемнәрен ныгыту. Сүз байлыгын үстерү. | *Парамон. 214 бит* |
| **ЯНВАРЬ** | | | |
| 1 | “Кар ява” | 1. Балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү; кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү; сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белүләренә ирешү.<br>2. Балаларның игътибарын, диалоглы сөйләмен, сөйләм сулышын; рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентлашуларын үстерү.<br>3. Башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү | *Хәзрәтова 89 бит.* |
| 2 | “Җиргә ап-ак кар ява” | Бәйрәмнән алган шатлыклар белән уртаклашу. Балаларны аралашуга тарту. Сөйләм телен үстерү. К авазын ныгыту. | *Парамон. 310 бит* |
| 3 | “Кар бабай” | Өйрәнгән авазларны ныгыту. Балаларны сөйләшүгә тарту. Балаларның ишетү сәләтен үстерү. | *Парамон. 346 бит* |
| **ФЕВРАЛЬ** | | | |
| 1 | “Очучылар” | 1. Балаларны самолетның өлешләрен, зурлыгын, формасын билгеләргә һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүгә күнектерүне дәвам итү; очучы, очып китү, очып төшү, аска, өскә, уңга, сулга, самолет сүзләре хисабына сүзлекне ак- тивлаштыру.<br>2. Балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирүләренә ирешү, игътибарларын үстерү.<br>3. Очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү. | *Хәзрәтова 92 бит.* |
| 2 | “Ватанны саклаучылар көне” | 1. Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү.<br>3. Ватан сакчыларына карата хөрмәт, патриотик хисләр | *Хәзрәтова 92 бит.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тәрбияләү. | |
| 3 | “Йомшак су, йөгерек су! ” | Балаларны уенга тарту. 2-3 сүзне кушарга өйрәтү. В, Ф авазларын ныгыту. Балаларның дикциясен, артикуляцион аппаратын үстерү. | *Парамон. 398 бит* |
| 4 | Әтиләр һәрчак кирәк” | Балаларны аралашуга тарту. Өйрәнгән авазларны ныгыту. Сөйләм телен үстерү. | *Парамон. 417 бит* |
| **МАРТ** | | | |
| 1 | “Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!” | 1. Балаларның әниләр бәйрәме турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтүләрен камилләштерү; әңгәмәдә катнашуга тарту.<br>2. Балаларның игътибарын, аңга алуларын, хәтерен, диалогик сөйләм формасын үстерү.<br>3. Балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. | *Хәзрәтова 94 бит* |
| 2 | Рус халык әкиятен сөйләү. “Теремкәй” | 1. Балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү.<br>2. Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Сорыколак, аю-Камытаяк сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү.<br>3. Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. | *Хәзрәтова 96 бит* |
| 3 | “Песидә кунакта” | Савыт-сабаларның исемнәрен ныгыту. С авазын тикшерү. Хайваннарның балаларының исемнәрен кабатлау. Сүз байлыгын үстерү. | *Парамон. 471 бит* |
| 4 | “Кояшка шатланабыз” | К, С авазларын ныгыту. Балаларның сәнгатьле сөйләм телен үстерү. Балаларда кызыксыну уяту. | *Парамон. 489 бит* |
| **АПРЕЛЬ** | | | |
| 1 | “Яз житте” | 1. Язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү. 2. Балаларның аңга алуларын, монологик сөйләмен үстерү.<br>3. Балаларда язгы табигатьтәге үзгәрешләргә кызыксыну тәрбияләү. | *Хәзрәтова 97 бит.* |
| 2 | “Бозау, колын, бәрән турында сөйлибез” | 1. Язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү; тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне (зур – кечкенә, калын – нечкә) таба һәм куллана белергә өйрәтүне дәвам итү; балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен ныгыту.<br>2. Балаларның аңга алуларын, монологик сөйләмен үстерү.<br>3. Балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. | *Хәзрәтова 97 бит.* |
| 3 | “Табышмак әйтәм” | Балаларны уенга тарту. Бер-берсе белән аралашырга өйрәтү. Өйрәнгән авазларны кабатлау. Балаларның дикциясен, артикуляцион аппаратын үстерү. | *Парамон. 506 бит* |
| 4 | “Оча, очмы” | Балаларны уен-аралашуга тарту; игътибарлыкларын үстерү. З авазын дөрес әйтергә өйрәтү; сүз байлыгын үстерү. | *Парамон. 561 бит* |
| **МАЙ** | | | |
| 1 | “Автобуста сәяхә” | 1. Балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү; йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту; йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү.<br>2. Кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелә торган сүзләр хисабына | *Хәзрәтова 101 бит.* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | сүзлекләрен активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү.<br>3. Тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү. | |
| 2 | “Мин җәйне яратам” | 1. Табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә кулланууларын активлаштыру; «бер», «күп» төшенчәләрен ныгыту; [з] авазын дөрес әйтергә өйрәтү.<br>2. Балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, аңга алуларын, уңай хис-кичерешләрен үстерү.<br>3. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү | *Хәзрәтова 103 бит.* |
| 3 | “Кем ничек коена? ” | Хайваннарның исемнәрен ныгыту. Авазларны кабатлау. Балаларның дикциясен, артикуляцион аппаратын үстерү. | *Парамон. 597 бит* |
| 4 | “Авазларны кабатлау” | Рәсемнәргә карап әйберләрнең исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү. Авазларның әйтелешен тикшерү, ныгыту; сүз байлыгын үстерү. | *Парамон.* 616 |

**2.5.4 Рәсем ясау буенча перспектив планлаштыру**

Л.А.Парамонова, Развивающие занятия с детьми 3-4 лет. Москва. ОЛМА Медиа Групп. 2013.

| № | Занятие темасы | Максат ориентирлары | Сылтама |
|---|---|---|---|
| | | **СЕНТЯБРЬ** | |
| 1 | “Төсле карандашлар” | Балаларны төсле карандашларны дөрес тоту, дөрес ясау тәртибе белән таныштыру. Рәсем ясау теләге уяту. | *21 бит* |
| 2 | “Буяулар белән танышу” | Балаларны гуашь белән, кәгазьдә пумала белән дөрес ясау алымнары белән таныштыру. Буяу белән рәсем ясау теләге уяту. | *39 бит* |
| 3 | “Балалар бакчага бара, юлда эзләре кала” | Пумаланы дөрес тотарга һәм буяулар белән дөрес ясарга өйрәтү. Төсләр белән таныштыруны дәвам итү. Пумала һәм су белән чиста, пөхтә эшләргә өйрәтү. | *54 бит* |
| 4 | “Көзге яфраклар” | Табигатьтәге үзгәрешләргә кызыксыну һәм күзәтүчәнлек уяту. Көзге яфраклар ясарга өйрәтү. | *70 бит* |
| | | **ОКТЯБРЬ** | |
| 1 | “Көзге чәчәкләр” | Күзәтүчәнлек, көзге чәчәкләрнең матурлыгын күрә белүне ныгыту. Чәчәкләр ясарга өйрәтү. Балаларның күзаллауларын ныгыту. | *109 бит* |
| 2 | “Алмагач” | Көзге үзгәрешләргә (көз килде, җиләк-җимешләр алып килде) кызыксыну уяту. Түгәрәк формалар ясарга, аларны буярга өйрәтү. Кул хәрәкәтләрен ныгыту. | *90 бит* |
| 3 | “Тиенкәй” | Рәсемне кирәкле урыннарында ясап бетерергә өйрәтү. Рәсемгә карата кызыксыну уяту. | *129 бит* |
| 4 | “Көз” | Табигатьтәге көзге үзгәрешләргә кызыксынучанлык һәм күзәтүчәнлек ныгыту. Агачларның, яфракларның коелуына матурлык хисе тәрбияләү. Мөстәкыйль рәвештә рәсем ясарга өйрәтү. Төрле төстәге буяулар белән пөхтә кулланууларына ирешү. | *149 бит* |
| | | **НОЯБРЬ** | |
| 1 | “Курчакның өе” | Әзер өйне бизәргә өйрәтү. Фломастерлар белән ясау алымын ныгыту. Рәсемгә карата кызыксыну уяту. Мөстәкыйльлек һәм сәнгатьлелек тәрбияләү. | *167бит* |
| 2 | “Курчакларга палас бүләк | Буяу белән дөрес кулланырга, пумаланы юып киптерергә куярга өйрәтү. Бизәү өчен төсләрне сайлый белергә өйрәтү. | *185 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итәбез” | Курчакларга бүләк ясау теләге уяту. | |
| 3 | “Курчак һәм аның дусларына киемнәр” | Кәгазь битен төрле сызыклар, нокталар, түгәрәкләр, таплар белән бизәргә кызыксыну уяту. Төрле төстәге буяулар белән рәсем ясарга өйрәтү. Төсләрне ныгыту. | *202 бит* |
| 4 | “Курчаклар саф һавага чыгалар” | Төсле битне бизәкләр белән бизәргә кызыксыну уяту. Мөстәкыйль рәвештә төсне һәм бизәкне сайларга, кәгазь битендә дөрес урнаштырырга өйрәтү. | *205 бит* |
| **ДЕКАБРЬ** | | | |
| 1 | “Ап-ак кар ява” | Балаларда күзәтүчәнлек, табигатьтәге үзгәрешләргә кызыксыну уяту. Пумала белән дөрес эш итүләрен булдыру. Буяу белән кәгазь битенең барлык җирендә, шулай ук агачларда кар ясарга өйрәтү. | *242 бит* |
| 2 | “Карлы урам” | Табигатьтәге үзгәрешләргә кызыксыну уяту. Пумала белән кар ясау алымын ныгыту. Рәсемгә карата кызыксыну уяту. | *262 бит* |
| 3 | “Шариклар, фонариклар һәм муенсалар” | Әзер формаларны бизәргә кызыксыну уяту. Буяулар белән төрле төсле нокталар, түгәрәкләр, дулкыннар ясарга өйрәтү. | *283 бит* |
| 4 | “Чыршыкай” | Яңа ел бәйрәменә карата кызыксыну уяту. Әзер чыршыга утлар ясарга өйрәтү. Төсләрне ныгыту. | *299 бит* |
| **ЯНВАРЬ** | | | |
| 1 | “Күңелле Петрушкалар” | Уен геройларына карата хис-тойгылырга бай җаваплылык уяту. Кәгазь битен төсле буяулар кулланып төрле бизәкләр белән бизәргә өйрәтү. Төсләрне ныгыту. | *316 бит* |
| 2 | “Кышкы күңел ачулар” | Өйрәнгән белемнәрен кулланып кышның билгеләрен күрсәтә белергә өйрәтү (кар, тау, кар бабай...). Кыш турында белемнәрен ныгыту. Рәсемгә карата кызыксыну уяту. | *338 бит* |
| 3 | “Мультфильм ясыйбыз” | Таныш булган геройларны ясауга кызыксыну уяту. Рәсемдә геройларның характерлы билгеләрен күрсәтә белергә һәм аны фломастер белән буярга өйрәтү. | *353 бит* |
| **ФЕВРАЛЬ** | | | |
| 1 | “Песиләр” | Хайваннарга карата кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. Өйрәнелгән белемнәрен кулланып таныш булган сурәт ясарга өйрәтү. Теләк буенча төсле карандашлар яки фломастерлар сайлау. | *370 бит* |
| 2 | “Әтиләр бәйрәме” | Хыял итү, сюжетлы уйнауны ныгыту. Рәсемне һәм аның детальләрен ясап бетерергә өйрәтү. Ватанны саклаучылар көне турында белемнәрен ныгыту. Балаларда кызыксыну уяту. Күңел күтәренкелеге булдыру. | *427 бит* |
| 3 | “Песиләр качканнар” | Сюжетлы уйнауны ныгытуны дәвам итү. Рәсемнәрне детальләр белән тулыландырырга (бүлмә, алан, ишегалды), персонажның үзенчәлекле билгеләрен күрсәтә белергә өйрәтү. Фломастер яки төсле карандашлар белән пөхтә буяуларына ирешү. | *373 бит* |
| 4 | “Әтәчкәй – алтын кикриккәй” | Рус халык әкиятенә кызыксыну уяту. Буяулар белән төрле бизәкләр ясарга өйрәтү. Төсләрне ныгыту. | *405 бит* |
| **МАРТ** | | | |
| 1 | “Яраткан әниемә чәчәкләр” | Якын кешеләргә карата дусларча караш тәрбияләү. Әниләрне котлау һәм аларга бүләк ясау теләге уяту. | *446 бит* |
| 2 | “Чебиләр” | Сюжетлы уйнауны ныгытуны дәвам итү. Буяулар белән | *481 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ясауны ныгыту. Рәсемгә кызыксыну уяту. | |
| 3 | “Без китаплар яратабыз” | Китап графикасы турында башлангыч белем бирү. Таныш персонажларның үзенчәлекле билгеләрен күрә һәм күрсәтә белергә өйрәтү. Пөхтә эшләүне ныгыту. | *495 бит* |
| 4 | “Китаплар” | Китап графикасы белән таныштыруны дәвам итү. Өйрәнгән белемнәрен кулланып таныш булган персонажлар ясарга өйрәтү. | *498 бит* |
| | | **АПРЕЛЬ** | |
| 1 | “Тамчы тама” | Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә һәм аларга карата кызыксынучанлык уяту (кар эри, тамчы тама). Тамчылар һәм күлдәвекләр ясарга өйрәтү. | *513 бит* |
| 2 | “Яз килде” | Балаларда күзәтүчәнлек ныгыту. Персонажга карата дуслык хисе тәрбияләү. Тал песие ботагындагы бөреләрне ясарга өйрәтү. | *532 бит* |
| 3 | “Кояшкай” | Кояш нурына карата эмоциональ караш уяту. Язгы үзгәрешләр турында белемнәрен тулыландыру. Буяу алымын ныгыту. | *550 бит* |
| 4 | “Тузганаклар (одуванчики)” | Күзәтүчәнлек, табигатьтәге үзгәрешләргә кызыксыну уяту (яшел чирәм, чәчәкләр). Яшел чирәм арасында сары тузганаклар ясарга өйрәтү. Пөхтә, чиста эшләүне ныгыту. | *568 бит* |
| | | **МАЙ** | |
| 1 | “Матур чәчәкләр” | Күзәтүчәнлек ныгыту. Лалә (тюльпан) ясарга өйрәтү. Үз рәсеменә карата соклану хисе уяту. | *585 бит* |
| 2 | “Рәсемнәр ясыйбыз” | Сюжетлы уйнауны ныгыту. Хайваннарга карата дуслык хисе тәрбияләү. Рәсемне ясап бетерергә, кырыйга чыкмыйча кирәкле төс белән буярга өйрәтү. | *603 бит* |
| 3 | “Күбәләкләр очалар” | Табигатьнең һәм күбәләкләрнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү. Төрле бизәкләр ясарга өйрәтү. Рәсемгә карата кызыксыну уяту. | *621 бит* |
| 4 | “Җәй җитә” (коллектив эш) | Коллектив эшкә кызыксыну уяту. Җәйге билгеләрне рәсемдә күрсәтә белергә өйрәтү. | *625 бит* |

### 2.5.5 Әвәләү буенча перспектив планлаштыру

Л.А.Парамонова, Развивающие занятия с детьми 3-4 лет. Москва. ОЛМА Медиа Групп. 2013.

| № | Занятие темасы | Максат ориентирлары | Сылтама |
|---|---|---|---|
| | | **СЕНТЯБРЬ** | |
| 1 | “Пластилин белән танышабыз” | Балаларны яңа материал- пластилин белән таныштыру. Аның йомшак, өзеп алып төрле әйберләр әвәләргә мөмкинлеге турында белем бирү. Такта өстендә ничек эшләргә кирәклеген аңлату. Чисталык, пөхтәлек тәрбияләү. Әвәләүгә кызыксыну уяту. | *24 бит* |
| 2 | “Балалар бакчасында уенчыклар” | Балаларны шар формасыннан уенчыкларның гәүдәләрен (аю, песи) әвәләргә өйрәтү. Мөстәкыйль рәвештә аларга хас булган билгеләрне өстәргә өйрәтү. Әвәләүгә кызыксыну уяту. | *42 бит* |
| | | **ОКТЯБРЬ** | |
| 1 | “Клумбада чәчәкләр” | Тирә-юнь белән танышканда күзәтүчәнлек тәрбияләү. Тәгәрәтү алымы белән әвәләргә һәм аларны тоташтырырга өйрәтү. Төсне күрә белүне ныгыту. | *113 бит* |
| 2 | “Куянкайга | Тәгәрәтү алымы белән әвәләргә өйрәтү. Пластилин һәм | *133 бит* |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кучтәнәч” | башка материаллар белән пөхтә эшләүләрен булдыру. | |
| **НОЯБРЬ** | | | |
